## ФАРАЗ ҺӘМ ӨМЕТ

Дәүләт Советында депутатлар нәрсә турында сөйләште?

> 2

## НӘРСӘ КӨТӘРГӘ?

Ил-көн вакыйгаларына «ВТ» хәбәрчесе күзәтүе

> 2

## БЕРЕНЧЕ УКЫЛЫШТА

Татарстан Республикасы бюджеты турында

> 3–4

## БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм ата-аналар өчен махсус сәхифә

> 6


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 156 (28929) | Шимбә | 22 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

vk.com

# ЧАБЫП БАРГАН АТ ТӨСЛЕ...

## ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЮЛЛАМАСЫ УҢАЕННАН УЙЛАНУЛАР

**Катлаулы һәм авыр сынаулар чорында яшибез. Әле март аенда гына, тиңе булмаган санкцияләр чолганышында калып, икътисад җимерелер, социаль тармакның асты өскә килер, тормышның башка өлкәләрендә дә зур төшенкелек хөкем сөрә башлар төсле иде. Чынлап та, Россия күләмендә зур проблемалар туды, чит илләр белән традицион элемтәләр өзелү, предприятиеләр арасында бәйләнешләрнең чәлпәрәмә килүе кыенлыклар өстенә кыенлыклар өстәде. Президентның Дәүләт Советына республика тормышының бөтен якларын иңләгән традицион Юлламасы шуңа күрә зур кызыксыну уятты. «Без ни хәлдә?», «Киләчәккә перспективалар нинди?» дигән сораулар тумый кала алмыйлар иде.**

Рөстәм Миңнеханов быелгы Юлламаны шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның «Татарстаным» шигыреннән өзек белән башлап җибәрде. Әйе, кайчандыр шагыйрь Татарстан картасының сурәтеннән зур мәгънә чыгарган, туган теле һәм иле булган халыкның киләчәгенә зур өмет белдергән иде. Ул юллар әле дә искермәгән, киресенчә, яңа төсмерләр белән тагын да байый төшкәннәр. «Дөньядагы гади булмаган агымдагы вазгыять барысын да үз урынына куйды һәм, беренче карашка, иң гади нәрсәләр бүген алгы планга чыкты», – диде бу хакта республика лидеры. Әйе, Татарстанның дөньяда тоткан урыны турында уйланабыз икән, без барысын да – дини һәм милли татулыкны да, бездә яшәүче һәр халыкның телләре сакланышы-үсешен дә, тән сәламәтлеген дә, рухи саулыкны да, гаилә ныклыгын да, кешеләрнең ил белән идарә итүдә ни дәрәҗәдә катнашуларын да, икътисадны да истә тотабыз. Президент һәр юнәлешкә тукталып, ирешелгәннәргә анализ ясады, киләчәккә максатлар билгеләде. Юллама бит 2023 елны күз алдында тотып язылган.

Уйлап карасаң, җәмгыять тормышының бар яклары үзара тыгыз бәйләнгән. Ныклы гаиләдән башка халыклар юк, телләрен, гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән халыклар арасында хезмәттәшлек була алмый, хезмәттәшлектән башка икътисад та юк, үсеш тә. Тулы канлы яшәеш өчен, бер төбәк халыклары гына түгел, халыкара мәйданда аркадашлык сорала. Татарстанның озак еллар дәвамында Ислам хезмәттәшлеге оешмасына кергән илләр белән аралашып-очрашып яшәве бүген үз сүзен әйтә. 13 нче Халыкара икътисади KazanSummitка быелның маенда, Көнбатыш тарафыннан аяусыз санкцияләр кертелгәч, дөньяның 64 иленнән вәкилләр килүен искә төшерик әле. Ул саммит акрынлап Татарстанда гына түгел, бөтен Россиядә ислам финанслары институтын үстерүгә мөһим этәргеч бирде. Татарстан лидеры Юлламада ислам банкингы хакында: «Хәзерге вакытта федераль дәрәҗәдә кануни базасы формалашу төгәлләнеп килә», – дип белдерде. Процент капиталына корылган глобаль финанс системасы җимерелеп килгән бу чорда аңа алмаш-альтернатива булып ислам банкингы гына килә ала. Татарстан Россиянең шул финанс системасын беренче булып кулланачак төбәге итеп сайланды. Бу юнәлештә эш күптән бара бит инде, димәк, стратегия дөрес сайланган.

Икътисади яктан Татарстан үзен ышанычлы хис итә. Идел буе федераль округында сәнәгать җитештерүе индексы 109 проценттан артып киткән лидер төбәк ул. Президент быел төбәк тулай продукты 3,7 триллион сум тирәсе булыр, төзелеш эшләренең күләме 460 миллиардка җитәр, төп капиталга инвестицияләр 750 миллиард сумнан ким булмас дип фаразлый. Нефть-газ сәнәгате тармагы уңышлы эшли. «Татнефть»нең перспективалары өметле, кече нефть компанияләренең дә нефть чыгаруда тоткан өлеше 20 процентка кадәр җиткән. Иң мөһиме: чималның күп өлеше – 23 миллион тоннасы үзебездә эшкәртеләчәк. Татарстанда газ куллану күрсәткече кызыклы. Үткән ел ул 18,2 миллиард кубометр булган. Чагыштырыйк: халкы 10 миллионга якынлашып килүче Венгриядә 2020 елда 10,2 миллиард куб метр газ кулланганнар. Газ исә – социаль тармак күрсәткече дә, сәнәгать чималы да. Икътисади төшенкелек хәлендәге дәүләтләр аны куллануны киметәләр.

Ахыры 2 нче биттә >

## Егетләребез өчен

КФУның Дизайн һәм пространство сәнгате институты студентлары мобилизациягә эләккән ир-егетләр өчен экипировка тегә башлаган. Бу хакта университетның матбугат хезмәте хәбәр итә. «Фәнни консультантыбыз Евгений Жемков – махсус хәрби операциядә катнашкан кеше. Ул безгә мобилизациягә эләккәннәр өчен эшләнмәләрнең сызымнары белән ярдәм итә», – дигән институтның дизайн һәм милли сәнгать кафедрасы мөдире Венера Юмагулова. Студентларның максаты – хәрбиләр өчен уңайлы булган, аларны саклый алырдай эшләнмәләр әзерләү. Әйтик, алар терсәк өлешенә юеш кертми торган чыдам күлмәкләр, муенны каплый торган махсус балаклавалар, берничә кесәле жилетлар тегәчәк. Киемсалым һәм экипировка әзерләү өчен кирәкле бөтен әйберне иганәчеләр акчасына сатып алачаклар. Үрнәкләрне кыр шартларында «Тимер», «Алга» һәм «Барс» батальоннары егетләре сынап карар дип көтелә.

Сүз уңаеннан, Россия Президентының матбугат сәркатибе Дмитрий Песков илдә өлешчә мобилизация тәмамлану турында сөйләшергә иртәрәк булуын әйтте. «Кайбер төбәкләр әлеге процессны инде төгәлләсә дә, кайберләрендә мобилизация әле дә дәвам итә», – дигән ул. Владимир Путин бер атна элек мобилизациянең октябрь азагына тәмамлану ихтималы булуын әйткән иде. Песков исә шуннан да төгәл датаның булмавын ассызыклады.

## *Күперле булачаклар*

Бу ел ахырына кадәр Татарстанда 22 күпер кулланышка тапшырылачак. Әлеге эш «Имин һәм сыйфатлы юллар» илкүләм проекты кысасында башкарыла. Татарстанның Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, хәзерге вакытта барлыгы 12 күпер төзекләндерелә, 15 күпердә ремонт эшләре бара. «Гомуми озынлыгы 302,8 метр тәшкил итә торган тугыз күперне кулланышка тапшырдык инде. Ел тәмамланганчы, тагын 13 күпердә эшләр төгәлләнер дип көтәбез», – диелә хәбәрдә.

Әйтик, Кайбыч районындагы Олы Кайбыч белән Камыллы авыллары арасындагы Гөбенә елгасы аша салынган күпердә капиталь ремонт эшләре тәмамланган. Лаеш районының Столбище авылына илтә торган күпердә дә ремонт эшләре төгәлләнгән.

## Торак алучылар кимегән

Татарстанда бу елның сентябрендә торак сатып алу буенча 7761 килешү төзегәннәр. Бу – августта теркәлгән саннан беразга гына кимрәк дигән сүз. Җәйнең соңгы аенда 7783 килешү төзелгән булган. Бу хакта Росреестрның республика буенча идарәсе хәбәр итә. Сентябрьдә килешүләрнең 2595е республика башкаласына туры килә. 2144 килешү ипотека кулланып төзелгән. Гомумән алганда, узган айда Татарстанда ипотека буенча торак сатып алуның 5270 очрагы теркәлгән. Моннан тыш, сентябрь аенда республикада җир кишәрлекләре сатып алу буенча 8107 килешү теркәлгән. Аларның 1163е Казанга туры килә.

Сүз уңаеннан, Татарстан – икенчел торак сатып алучылар саны буенча Идел буе төбәкләре арасында беренче урында. Беренчел базарда күчемсез милекнең 52 проценты кредит акчалары җәлеп итеп сатып алынса, икенчел базарда – 77 проценты.

Мөһим сөйләшү

# ҮЗӘКТӘ – КЕШЕ

**Эчтәлекле, максатчан, мөһим һәм кеше турында. Казан (Идел буе) федераль университеты каршындагы иҗтимагый-сәяси һәм этноконфессиональ мәсьәләләр буенча эксперт советы вәкилләре, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Дәүләт Советына еллык Юлламасы турында фикер алышканда, шул сүзләрне еш кабатлады. Республика җитәкчесенең Юлламасы хакимият вәкилләренә генә түгел, халыкка мөрәҗәгать булып та яңгырады. Бурыч-максатлар билгеле, эшләргә вакыт. Белгечләрнең бу җәһәттән фикерләрен без дә тыңладык.**

Университет каршындагы советның җаваплы сәркатибе Андрей Большаков быелгы Юлламаның эчтәлек һәм рух ягыннан да үзгәрүенә игътибар итте.

– Былтыргы Юллама кешеләрнең тормыш сыйфаты, социаль проблемаларга йөз тоткан, аерым алганда, позитив рухтагы мөрәҗәгать булса, быел исә, хәрби операциягә бәйле рәвештә, эчтәлек тә үзгәреш кичерде. Рөстәм Миңнехановның төп чыгышы мобилизациягә бәйле иде. Төгәлләштереп әйткәндә, сүз хәрбиләрне махсус хәрби операция зонасына җибәрү турында гына түгел, икътисади, идарә итү мәсьәләләренә бәйле мобилизация турында да бара. Президент икътисади сорауларга күп игътибар бирде, – дип саный белгеч.

Шулай да асыл мәгънә үзгәрешсез кала. Бу – рухи, тормыш кыйммәтләре, ныклы нигез. Дәүләт Думасы депутаты Олег Морозов шуны ассызыклады. Аның сүзләренчә, әнә шул кыйммәтләр барлык бурычларны хәл итүдә ярдәмче булачак та.

– Башыбызда, күңелебездәге эчтәлек нинди булачак, мәктәптә, вузда, урамда нәрсә турында сөйләшербез, үз-үзебезгә биргән сорауларга нинди җавап табарбыз, гаиләләрдә үзебезне ничек тотарбыз – шулар мөһим. Юлламада боларга басым ясалуы, минемчә, бик тә дөрес. Хәзер һәр кеше сафта үз урынын табарга тиеш, – диде депутат.

Гомумән, фикер алышуда катнашучылар беравыздан Юлламаның үзәгендә кеше һәм кеше тормышы торуын билгеләп узды. Бу фикерне сәясәт белгече Марат Бәширов та әйтте.

– Юлламада әйтелгәннәр гади кешеләрнең тормышына кагылышлы иде, – диде ул. – Рөстәм Миңнехановтан ишеткән сүзләр – бик мөһим сүзләр ул. Аларны, дөресен әйткәндә, һәр төбәк башлыгы әйтергә тиештер. Рөстәм Миңнеханов кече һәм урта бизнес вәкилләре турында да әйтте, миңа шунысы да ошады. Хәзерге вазгыятьтә бу бик мөһим. Татарлар – эшлекле халык. Без үзебезне тәэмин итәргә сәләтле. Зур предприятиеләр, оешмалар эш урыннары булдыра, ярдәм чаралары тәкъдим итә. Иртәме-соңмы, тынычлык урнашыр, киткән хәрбиләребез дә әйләнеп кайтыр, икътисад да тотрыкланыр. Әмма иң мөһиме – балансны саклау.

Ахыры 5 нче биттә >

Сүзгә-сүз

**Михаил МИШУСТИН, Россия Хөкүмәте Рәисе:**

Россия глобаль сәүдәнең мөһим өлеше булып кала бирә һәм безнең илне бу процесстан кысрыклап чыгарырга тырышу абсурд булып күренә. «Дус» булмаган илләр белән сәүдә кимүгә карамастан, Россиянең башка партнерлары белән товар әйләнеше арта.

**(«Сделано в России» форумындагы чыгышыннан)**

## РОССИЯДӘ – ХАЛЫК САНЫ

**Илдәге халыкның яшь структурасы буенча нинди үзгәрешләр бар? «Меркатор» белгечләре шуны ачыклаган.**

2022 ел башына Россиядә яшәүчеләр саны **145,6 млн**

**27,3 млн** – хезмәткә яраклы яшькә җитмәгән

**83,2 млн** – хезмәткә яраклы яшьтә

**35,0 млн** – хезмәткә яраклы яшьтән өлкәнрәк

## *Ягулык бәясе төшкән*

Узган атнада, ягъни 10–17 октябрь арасында Татарстанда дизель ягулыгының бәясе 2 тиенгә арзанайган. Хәзер аның уртача хакы – 52,8 сум. Бу хакта Татарстанстатка сылтама белән «Татар-информ» хәбәр итә. Бензин бәясенә килгәндә, үзгәрешләр юк. АИ-92нең бер литры – 45,94 сум, АИ-95неке – 49,41 сум, ә АИ-98неке – 60,76 сум.

Сүз уңаеннан, узган елның декабре белән чагыштырганда, АИ-92нең бәясе – 4 тиенгә, ә АИ-95 бензинының бәясе 10 тиенгә арзанайган. АИ-98нең бәясе, киресенчә, 2,86 сумга арткан. Дизель ягулыгына бәя узган ел ахырыннан 1,91 сумга кыйммәтләнгән.

vk.com

## ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

# *Албасты ничек ярала?*

Үткән XX гасырның янә дә бер әшәкелеге: ул җирдә фашизм дип аталган, кеше затын бөҗәктән артыкка санамаган сәяси агым һәм күренеш тудырды. Моннан нәкъ 100 ел элек, 1922 елның октябрендә, моңарчы ирек-хөрлекне алга сөреп яшәгән Европа кыйтгасында, Италиядә беренче тоталитар диктатура ялып, властька «фашо» (берлек) атлы радикаль оешма – Бенито Муссолини һәм аның тарафдарлары килде.

Тагын 11 ел үтүгә, тагын да шул Европада, киң җәмәгатьчелек башта абайламыйчарак калган күпкә хәтәррәк вакыйга күзәтелде: 1933 елда Германиядәге хакимияткә Гитлер менеп урнашты. Ни өчен хәтәррәк? Чөнки, пәри башка, җен башка, дигән кебек, нацизм – фашизмнан да кабахәтрәк нәрсә.

Нацизмның чишмә башы саналырга лаеклы агым – фашизм төбендә баштан ук тоталитарлык ятып, адәм баласын ул дәүләтнең кечкенә бер шөребе итеп күргән һәм күрә. Кеше, аның тормышы, мәнфәгатьләре, хәтта гомере дә – барысы да дәүләт, аның егәре, бөеклеге, яулап алулар өчен. «Урта диңгез – итальян күле. Италия – Рим империясенең дәвамчысы, ул «күнитек»кә – Апеннин ярымутравына гына сыешып яшәргә тиеш түгел». Фашизмның нацизм белән чагыштырганда «әйбәт»леге шунда: аның асылында расачыл теория – бер халыкның калган халыклардан өстенлеге юк. Нацизм исә бер милләтне – үз кешеләрен генә кешегә саный, калганнар барысы да – түбән сортлы, адәм булып җитә алмаган кавемнәр. Андыйлар йә юкка чыгарылырга, йә «югары сортлы» халыкка хезмәттә торырга тиеш.

Терминологиягә кереп киткәч, тагын да бер ачыклык кертәсе килә. Ни өчен без Германиядә ялган канечкеч ул көчне Бөек Ватан сугышы дәвамында да, аннан соң да фашизм дип атадык? Дөрес, «нацизм» төшенчәсе дә кулланылды, тик сирәгрәк. Җавап шундый: нацизм ул – национал-социализм, шуның кыскача әйтелеше. Үзе дә социализм төзеп яткан СССРга андый кәлимәне куллану ул чорда бер дә отышлы булмый. Ә «фашизм», «фашист» – яңгырашлы сүзләр. Нәкъ шуңа күрә иң әшәке адәм актыклары турында әйткәндә, без бүгенгә чаклы шул төшенчәне кулланабыз. Гәрчә, мәсәлән, шул ук Гитлерны, аның тирәсендәгеләрне фашист дип атау дөрес булмаса да.

Нацизм – фашизмның эволюциясе, аның тагын да әшәкеләнүе – мондый билгеләмә дә яшәргә хаклы кебек. Тик нацизм тумаса, «фашист» сүзе бүген ул кадәр нәфрәт белән яңгырамас иде. Җир йөзендә тирания, шәхес культы, диктатуралар аңынчы да булмаган түгел, булган – Муссолини да үзенең фашизмы белән, ихтимал, инде онытылган да булыр иде. Тик менә онытмадык. Нинди дә булса кабахәтлек, ерткычлык, кешелексезлек турында сүз чыкканда, без ул төшенчәне бик теләп кулланабыз.

«Дуче» фашизмын, Италияне читкәрәк куеп, бу юллар авторы күп еллар буе аңларга тырышып йөргән, соңгарак калып аңлаган сорауга күчәсе килә. Ничек инде XX гасырда мәгърифәтле кыйтга – Европада, ул гынамы, кешелек дөньясына күпме мәшһүр затларны – Гегель, Кант кебек бөек философларны, Гете, Шиллер кебек даһи шагыйрьләрне, Бах, Бетховен кебек композиторларны, санасаң, тагын әллә кемнәрне биргән илдә нацизм дигән мәхшәр, аның атасы Гитлер ярала алган? Европада гына түгел, дөньяда иң алдынгы милләтләрнең берсе, аның зыялылары, фикер ияләре нәрсә караган? Ничек фюрер ул халыкның башын шулай тиз һәм нәтиҗәле әйләндерә алган?

Алдынгымы, түгелме, халыкны үз артыннан ияртү өчен, беренчедән, аның авырткан җиренә басарга, икенчедән, һәрдаим ул халыкның бөеклеген искәртеп торырга кирәк икән. Авырткан җир – алманнарның Беренче Бөтендөнья сугышында җиңелүе, Германия өчен хурлыклы Версаль килешүе. Халыкның күңелендә яткан кимсенү, шул хис тудырган реванш кәефләре. Ә бөеклек дигәндә, алман халкы үзенең бөек уллары күплеге, үзенә хас холык-фигыле, булдыклылыгы ягыннан күпләргә үрнәк икәнен болай да белгән булса кирәк. Бөеклек белән исерү дигәндә, даһилары, башкалар шаккатарлык казанышлары аз булган, зурлыкны бөеклек белән бутаган кайбер башка халыкларның да андый чир белән чирләгәнен беләбез.

Ләкин «авырып йөреп» тә башкаларга зыян китермичә яшәргә, чыгырдан чыкмаска мөмкин. Гавамны тәмам аздыру, анда агрессия уяту, илне милитаристик рельсларга куюда нәрсә төп рольне уйный һәм уйнаган соң? Германиядә дә, Италия очрагында да пропаганда һәм агитация. Безнеңчә әйткәндә, үгет һәм коткы. Теләсә кайсы илдә теләсә кайсы халыкны нинди дә булса ялган хаста – бөеклек, өстенлек белән чирләтеп кенә калмыйча, аны башка халыкларга өстерәсе, юнәлтәсе килгәндә, ансыз һич булмый. Өченче Рейхның пропаганда министры Геббельснең: «Сез миңа массакүләм мәгълүмат чараларын гына бирегез, мин теләсә кайсы халыктан дуңгыз көтүе ясыйм», – дигән сүзләре пропаганданың көчен, аның әшәкелеген тулысынча ачып салмыймы? Сала. Күрүебезчә, мәгърифәтле, аңлы алман халкында да аңа каршы торырлык гайрәт булмаган. «Мең тапкыр кабатланган ялган дөреслеккә әверелә». «Пропаганда кешенең акылына түгел, хисенә тияргә, хис аша аның белән идарә итәргә тиеш». Болары да – шул нацист, шул коточкыч зат әйткән сүзләр.

Коткы-үгет кенә димәгән, шул ук идеология дә, «кызыл»мы ул, алманнардагыча «көрән», итальяннардагы кебек «кара»мы, халыкны көтү итүдә олы роль уйный. Җәмгыять сәламәт булсын дигәндә төп шарт – анда фикер төрлелеге булдыру, аны саклау, пропагандадан ваз кичү кирәк. Ул шартлар үтәлми икән, Оруэллның мәшһүр романындагы Дөреслек министры ялып, ул гамәлгә керткән коточкыч шигарьләр («Ирек ул – коллык», «Белмәү – көч», «Сугыш ул – тынычлык») эшләп китү мөмкинлеге арта. Ә бу – ул ил өчен генә түгел, бик күп башка халыклар, илләр, дөнья өчен дә фаҗига...

Кайдадыр кайсыдыр халык үз җитәкчеләренә, алар тудырган идеологиягә табына башлый, пропагандадан исерә икән, бәла чыгасын көт тә тор. Гавам, беркатлыланып, дәүләткә сәясәт, икътисад, законнарны гына түгел, үз вәкаләтләрен дә биреп бетерә – иреге, намусы, хәтта гомерен дә дәүләткә ышанып тапшыра икән, ул фикерләүдән туктап, йокы, зомби хәленә кереп кенә калмый, абсолют властька, явызлыкка, тетрәнүләргә дә юл ача. Андый очракта «Власть хакимне боза, абсолют власть – абсолют дәрәҗәдә боза»дан да бигрәк, гавамдагы йокы, зиһен йокысы албастылар тудыра («Сон разума рождает чудовищ») башлый.

## ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

# Һәркем җаваплы

**Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия Президенты Указы белән каралган чараларны гамәлгә ашыру буенча төбәктәге оператив штабның беренче утырышын үткәрде. Искәртеп узыйк: дәүләт башлыгы төбәк башлыкларына үз территорияләрендә иминлекне тәэмин итү мәсьәләләрен шәхси контрольгә алырга кушкан иде.**

Республика оператив штабын Рөстәм Миңнеханов җитәкли. Премьер-министр Алексей Песошин һәм Президент Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров урынбасарлар итеп билгеләнде. Моннан тыш штаб составында министрлык, федераль башкарма хакимият органнарының урындагы вәкилләре дә бар.

Утырышта җәмәгать тәртибен тәэмин итү, транспорт, торак-коммуналь хуҗалык системасы, энергетика мәсьәләләре каралды.

– Һәркем ил җитәкчелеге куйган бурычларны гамәлгә ашыруда җаваплылыкны аңларга тиеш, – дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов.

# *Парклы да булдылар*

**Хәзер Казанның «Салават Күпере» торак комплексында яшәүчеләргә ял итү өчен шартлар тагын да яхшырды. Комплекстагы яңа паркны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та карады.**

Сүз уңаеннан, «Салават Күпере»ндә 30 меңләп кеше яши. Биредә балалар бакчасы, мәктәп һәм башка төр инфраструктура объектлары төзелгән иде инде. Гаилә белән ял итәр өчен мәйданчык булмаган. Хәзер биредә яшәүчеләр 6 га мәйданны биләгән яңа паркка ия булды.

Әлеге паркта балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары да, экстрим-зона да каралган. Тән өчен генә түгел, күңел өчен дә булсын дип, паркның бизәлеше турында да онытмаганнар. Фонтан, яр буеннан йөрү өчен махсус зона, амфитеатр ясаганнар, таганнар урнаштырылган.

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов, төзекләндерелгән объектлар белән танышып, «Салават Күпере»ндә яшәүчеләрнең хәлен дә белеште. Моннан тыш Президент этләрне йөртү өчен махсус мәйданчыкны да барып күрде. Аны оештыру турында биредәге эт асраучылар һәм архитекторлар күптән хыяллана иде инде. Хәзер дүрт аяклы дуслар өчен 700 квадрат метр мәйданчык билгеләнгән.

Моннан тыш Рөстәм Миңнеханов агач утыртуда да катнашты.

# ЧАБЫП БАРГАН АТ ТӨСЛЕ...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Чит ил компанияләренең безне ташлап китүе Татарстан предприятиеләрен куркытмаган, күп кенә очракларда үсеш өчен яңа мөмкинлекләр генә ачкан. КАМА TYRES компаниясе, мәсәлән, шин җитештерүне модернизацияли, 7 миллиард сумлык инвестицияләр ясый. Газета хәбәрчесе статистиканы махсус карады: шиннар җитештерү узган елгының 103,6 проценты күләмендә. Икътисади элемтәләр өзелгәч, КАМАЗ кыен хәлдә калган иде. Әмма завод киләсе елның беренче кварталында яңа буын К5 модель рәтенә караган яхшыртылган сыйфатлы йөк машиналары җитештерә башларга җыена. Казан авиация заводы гражданлык очкычы булган ТУ-214 самолетын бер елга 20не җитештерерлек куәткә ия. Казан вертолет заводы исә бер елга 100 вертолет җитештерүне үзенә максат итеп куйган. 2021 елда 45 вертолет җитештерелүен исәпкә алганда, үсеш темплары зур булырга вәгъдә итә. Яңа төр технологик продукция җитештерергә әзерләнгән заводлар байтак. Әйтик, Чистайдагы «Бетар» компаниясе су хисаплагычлар белән генә канәгатьләнми, робот-манипуляторлар җитештерүче яңа мәйдан әзерли. Кыскасы, Татарстан сәнәгате төшенкелектә түгел, күтәрелештә.

Бездә индустриаль парклар челтәре уңышлы үсә, инженер-техник кадрлар әзерләү яхшы оештырыла. Студентларны завод инженерлары укыта торган үзәкләр саны арта.

Авыл хуҗалыгы тармагы быел аеруча уңышлы эшләде. 5 миллион тонна бөртекле ашлык җыелды. 2021 елдагыдан ике тапкырдан да күбрәк бу. Башка төр культуралар уңышы да начар түгел. Татарстан азык-төлек белән үзен тулысынча тәэмин итә. Иң мөһиме: продукция җитештерелеп кенә калмый, күпчелек өлеше үзебездә эшкәртелә. 5 ел элек сөтнең 50 проценты гына үзебездә эшкәртелсә, хәзерге күрсәткеч – 91 процент.

Президент Юлламасындагы икътисади уңышлар, тормышка ашырылган технологик юнәлешләрне санап бетерерлек түгел. Болар барысы да – җәмгыять тормышының төрле тармакларының уңышлы ярашуы нәтиҗәсе. Технологияләрдән башка икътисади күтәрелеш юк, мәгариф һәм кадрлар әзерләү системасыннан башка технологияләр була алмый, җәмгыятьтә татулык булмаса, барысы да җимерелә. Президент Юлламасын укыганда, шулар хакында уйландым. Татулыкны җимерү өчен ялган мәгълүмат тарату да җитә. Мәгълүмат кырында бүген эш моннан берничә ел элеккегә караганда катлаулырак. Бу – Президент фикере. Шуңа күрә лидер республика Хөкүмәтенә дәүләтнеке булган массакүләм мәгълүмат чараларын реформалау чараларын эшләргә йөкләве хакында да әйтә. Мөһим бурыч бу. Фейклардан азат булган, хакыйкатьтән курыкмый торган мәгълүмат чарасы булдыру хәзерге чорда җиңел эш түгел. Республикабызның картадагы сурәте генә түгел, үзе дә, шагыйрь язганча, чабып барган ат төсле булуы хакына барлык бурычларны да комплекслы рәвештә уңышлы тормышка ашырырга кирәк булачак.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**Татарстан Республикасында 2023 елны Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан итү турында**

Рухи хәзинәләрне саклау һәм баету, борынгы милли гореф-гадәтләрне яңадан торгызу максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасында 2023 елны Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан итәргә.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын уздыруның төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештырырга.
4. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.
5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.
6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 20 октябрь
№ ПУ-750

# ШУЛАЙ ДИП УЙЛАП ТОРЫЙК

**ТР Дәүләт Советында**

**«Әлеге дә баягы, Сәрби әби таягы» дигәндәй, Дәүсовет утырышларында һәр чыгышның Украинадагы хәлләр, санкцияләрнең икътисадка, гомумән, ил тормышына тискәре йогынтысы турындагы сүзләр белән башлануына тәмам күнегеп беттек. Инде безне бу хәлләр артык куркытмый да кебек тоела башлады. Куркытыр да иде, мөнбәргә күтәрелүчеләр, илнең, республикабызның финанс-икътисади хәлен тотрыкландыру, хәтта үсешкә таба атлау өчен нинди ярдәм чаралары кабул ителү турында сөйләп, күңелне тынычландырырга омтылалар.**

Татарстан Премьер-министры урынбасары, икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов әйтүенчә, бүген безгә карата 11 меңнән артык санкция кулланыла икән һәм чикләүләр басымы тагын да арта башларга мөмкин. Шуңа күрә алдагы көнгә план кору шактый ук дәрәҗәдә «шулай дип уйлап торыйк»ка нигезләнә. Быел без 3,7 триллион сумлык төбәк тулай продукциясе җитештерелер дип уйлап торабыз. Киләсе ел йомгаклары буенча әлеге санның 3,9 триллионга җитәчәгенә өметләнәбез. Сәнәгать үсеше индексы 100,7 процент тәшкил итәр дип фаразланган инде.

Базардан чит ил компанияләре китүен дә хәерлегә юрыйбыз әле, үзебезнең җитештерүчеләргә алар урынын алу мөмкинлеге туды, дибез. Һәрхәлдә, икътисад министры шул фикердә. Бөтен эш уй-фикердән башлана инде ул. «Изге урын буш тормый» дип, җиң сызганып эшкә тотынырга иде. Акыл өйрәтү дип кабул ителмәсен, без акрын кыймылдыйбыз шикелле. Санкцияләр кертелә башлаганга инде сигез ел вакыт узды, хәзергә әллә ни майтара алмадык кебек. Мөгаен, «авось»ка өметләнгәнбездер, «үзебездә җитештерү», «импорт алыштыру» кебек сүзләр һаман да телдән төшми. «Озак җигәбез, тиз барабыз», – дип күңелне тынычландырсак кына инде.

Безнең халык эштән курыкмый, аңа бары тик аяк чалма, шартлар гына тудыр. Киләсе елга кече һәм урта эшмәкәрлеккә зур игътибар бирелер һәм бу өлкәдә эшләүчеләр саны 804 меңнән артык булыр дип уйлап торалар. Тик аларга дәүләт ярдәме вакытында булсын иде. Юкса, районнарда йөргәндә, безгә эш кешеләренең зарларын да шактый ишетергә туры килә.

Авыл хуҗалыгына килгәндә, киләсе елга 280 млрд сумлык продукция җитештерелер дип уйлап торалар.

2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проектына килгәндә, заман кыенлыкларына карамастан, аңа тел-теш тидерерлек түгел иде. Шулай да депутатлар финанс министры Радик Гайзатуллинга шактый сорау бирделәр. Аларны өлешчә мобилизациягә бәйле чыгымнар да, бюджет кытлыгының 27 млрд сумга җитүе һәм бу кытлыкны нинди акча хисабына каплау да кызыксындырды. Депутатларны министрның, Бюджет, салымнар һәм финанс комитеты рәисе Леонид Якунинның җаваплары канәгатьләндерде үзе. Леонид Александрович әйтмешли, бюджет заман чакыруына җавап бирерлек итеп эшләнгән. Тик Дәүсоветтагы КПРФ фракциясе рәисе Хафиз Миргалимов кына бюджеттан бик үк риза-бәхил түгел иде. Аның әйтүенчә, илдә 20 млн кеше – хәерчелек чигендә. Куллану бәяләре котырып үсә, ә хезмәт хакы, пенсияләр җитәрлек артмый. Күпме кеше «зарплатадан зарплатага» яши. Хафиз иптәш фикеренчә, бездә хезмәт җитештерүен арттырып, куллану бәяләрен төшерергә, үзебез җитештергәнне сату буенча ил эчендә сәүдәне җанландырырга кирәк. «Россиядә утыз ел буе капитализм төзиләр, ә ул ковид белән авырый», – дип, образлы итеп сүзен тәгәлләде депутат.

Бер уйлаганда, Хафиз Гаяз улының фикерләрендә хаклык та бар. Без гаять бай илдә яшибез һәм бөтен нәрсәне үзебез җитештерә алабыз, кеше кулына калу куркынычы юк. Ә икенче уйлаганда, бүгенге сәясәт шуңа таба бара да инде. Һәрхәлдә, шулай дип уйлап торыйк.

tatarstan.ru

Утырышта ике яңалык ишеттек. Беренчесе Татарстанда Конституция суды бетерелү иде. Бу «изге» эш өчен махсус комиссия төзелгән инде. Депутат Ркаил Зәйдулла: «Суды бетерелгәч, Конституция үзе дә юкка чыгарылмасмы?» – дип сораган иде, парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин аны тынычландырды. Төбәкләрдәге Конституция судларын бетерү турында федераль закон чыккач, без аны үтәми булдыра алмыйбыз, диде. Ә «конституцион» бәхәсләрне гомумюрисдикция судлары һәм арбитраж судлар хәл итә ала. Закон проектын тикшерү исә нигездә, Конституция суды судьяларының социаль гарантияләрен саклап калуны хәл итүгә кайтып кала.

Икенче яңалык шулай ук «кызыклы» гына. Президент каршында рус телен саклау һәм үстерү буенча да махсус комиссия эшли башлаячак. Рус теле язмышы моңа кадәр эшләп килгән комиссия, ягъни татар телен һәм республикада яшәгән башка халыклар вәкилләренең телләрен саклау, үстерү комиссиясе эшчәнлегенә кагылмый икән. «Өлкән ага» теле өчен аерым комиссия оешу, бер уйлаганда, бик вакытлыдыр да. Чөнки бүген рус кардәшнең телен дә, үзен дә юк итү өчен тырышучылар шактый.

Бер мәкаләмдә «рус кардәш» дип язуыма бик бәйләнгәннәр иде. Янәсе, рус татарга каян килеп кардәш булсын, ди. Мин аларга: «Барыбыз да – Алтын Урда балалары», – дип җавап бирдем һәм тынычландылар тагын. Бер уйлаганда, без бит инде менә ничә гасыр руслар белән бергә яшибез. Халык шагыйре Зиннур Мансуров әйтмешли, җир астындагы бер тамырдан чыккан ике агач кебек. Әгәр татар телен бетерсәләр, рус теле дә юкка чыгачак. Шагыйрьнең ни әйтергә теләгәнен аңлагансыздыр инде. Бер үк җирдә гомер кичергән халыкларны уртак язмыш та көтә. Һәрхәлдә, шулай дип уйлап торыйк әле. Һәр милләтнең үз теле өчен үзе җаваплы икәнен дә онытмыйк. Бүген рус теленең ничек чүпләнгәнен, тәме беткәнен үзебез үк күреп торабыз. Татар теле белән дә шул ук хәл. Шөкер, соңгы вакытларда Дәүсовет утырышларында татарча чыгыш ясаучылар ишәя башлады. Йөз депутатның җитмешкә якыны татар. Шуның биш-алтысы, бераз оялып булса да, үз ана телләрендә бераз ермачлый бит әле. Тел саклауда рус кардәш тә безгә ярдәм итәр дип өметләнәбез. Һәрхәлдә, шулай дип уйлап торыйк.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

# ТАТАРСТАН БЮДЖЕТЫ: БЕРЕНЧЕ УКЫЛЫШ

## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ «2023 ЕЛГА, 2024 ҺӘМ 2025 ЕЛЛАР ПЛАН ЧОРЫНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫ ТУРЫНДА» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ ПРОЕКТЫН БЕРЕНЧЕ УКЫЛЫШТА КАБУЛ ИТТЕ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ УРЫНБАСАРЫ – ИКЪТИСАД МИНИСТРЫ МИДХӘТ ШАҺИӘХМӘТОВ ЧЫГЫШЫ

**Фаразлау параметрлары Хөкүмәт утырышында, Парламент тыңлауларында, Дәүләт Советы комитетлары утырышларында, республиканың муниципаль берәмлекләре катнашындагы республика киңәшмәсендә каралды.**

Агымдагы елда социаль-икътисадый үсеш фаразы икътисад үсешендәге югары дәрәҗәдәге билгесезлек шартларында формалаштырыла, ул күпчелек очракта геосәяси факторлар белән билгеләнә.

Кертелгән моңарчы күрелмәгән санкцияләр ил икътисады үсешенә зур чикләүләр куя:

– тышкы сәүдә эшчәнлегенә чикләүләр һәм транспорт блокадасы экспорт-импорт операцияләрендә чагылыш таба;

– технологик чикләүләр инвестиция проектларын тормышка ашыруга тәэсир итә;

– Россия компанияләренең һәм банкларының глобаль финанс системасына керү мөмкинлеген блокировкалау чит ил контрагентлары белән түләүләр үткәрү буенча шактый кыенлыкларга китерде;

– төрле гуманитар санкцияләр кешеләрнең бер урыннан икенче урынга хәрәкәт итүендә дә, белем бирү, мәдәни һәм спорт чараларын үткәрүдә дә чагылыш тапты.

Шул ук вакытта санкцияләр басымы статик (хәрәкәтсез) түгел, ул көчәячәк, шул исәптән, икенчел санкцияләр, экспортка өстәмә чикләүләр һәм санкция астындагы товарлар һәм технологияләр исемлеген тагын да киңәйтү өлешендә, бу киләчәктә үсеш шартларының билгесезлек факторын сизелерлек арттыра.

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы мәгълүматларына караганда, 11 меңнән артык санкция кертелгән инде.

Санкцияләр басымы шартларында республика предприятиеләре һәм оешмалары тарафыннан

– яңа кооперация элемтәләрен җайга салу;

– логистик чылбырларны үзгәртеп төзү;

– яңа сату базарлары эзләү;

– импортны алмаштыру буенча оператив рәвештә эш оештырылды.

Бизнеска ярдәм итү максатларында федераль дәрәҗәдә Тышкы санкция басымы шартларында Россия икътисады үсешен тәэмин итү буенча беренчел чаралар планы кабул ителде һәм гамәлгә ашырыла.

Күрсәтелгән планны тормышка ашыру кысасында түбәндәгеләр гамәлгә ашырылды:

– федераль исемлеккә кертелгән система барлыкка китерә торган оешмалар әйләнештәге акчаларын тулыландыруга 40 млрд сумнан артык ташламалы кредит алды;

– республика предприятиеләре һәм оешмалары иминият кертемнәре буенча 20 млрд сумлык кичектерүдән файдаланды;

– кече һәм урта бизнес предприятиеләренә 60 млрд сумнан артык ярдәм күрсәтелде.

Республика оператив штабы тарафыннан даими нигездә предприятиеләрнең проблемалы мәсьәләләренә карата тиешле чаралар күрелә.

Горький һәм Куйбышев тимер юллары, ташучы предприятиеләр белән берлектә йөк ташу белән бәйле мәсьәләләр каралды, конкрет карарлар кабул ителде, яңа логистика маршрутлары тәкъдим ителде.

Татарстан таможнясы белән товарларны таможня чиге аша күчерү мәсьәләләре буенча тышкы икътисадый эшчәнлектә катнашучылар өчен гамәлләрнең этаплы алгоритмы эшләнде.

Республика маркетинг үзәгенән файдаланып, элек сатып алына торган чит ил продукциясен алмаштыру өчен, Россиядән һәм дустанә илләрдән җитештерүчеләр продукциясенең 140 меңләп позициясе тәкъдим ителде.

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларын яңа шартларга яраклаштыру федераль һәм республика ярдәм чараларыннан максималь файдалану хисабына үткәрелә.

Дәүләт Думасы депутатлары һәм федераль министрлыклар белән берлектә республика предприятиеләре һәм оешмаларына ярдәм итү чаралары буенча тәкъдимнәр эшләнде һәм тиешле федераль хакимият органнарына кертелде.

Алдагы елларда салынган фундамент булу, предприятиеләрнең һәм оешмаларның өзлексез эшләве, кредит-финанс оешмаларының тотрыклы эшләве, федераль һәм төбәк ярдәм чаралары, милли проектларны һәм республика программаларын гамәлгә ашыру сәбәпле, 2022 ел йомгаклары буенча республиканың тулай төбәк продукты 3,7 (Өч бөтен уннан җиде) трлн сум дәрәҗәсендә бәяләнә.

Югары дәрәҗәдәге билгесезлекнең агымдагы шартларында 2023–2025 елларга Республиканың социаль-икътисадый үсешенең фаразланган күрсәткечләре түбәндәгеләр нигезендә формалаштырылды:

– илнең икътисадый сәясәтенең өстенлекләрен тормышка ашыру,

– шулай ук әлеге предприятиеләр һәм оешмалар, тармак министрлыклары мәгълүматларын,

– муниципаль берәмлекләрне үстерү фаразларын исәпкә алып,

– икътисадның тотрыклы үсеше һәм гражданнарның иминлеге өчен илкүләм проектларны, дәүләт программаларын, ярдәм чаралары комплексын гамәлгә ашыру.

2023 елда тулай төбәк продукты 3,9 трлн сум дәрәҗәсендә фаразлана.

Икътисад структурасында иң зур чагыштырма авырлыкны сәнәгать алып тора.

Предприятиеләр планнарын гамәлгә ашыруны исәпкә алып, сәнәгать җитештерүе индексы 2023 елда 100,7% (Йөз бөтен уннан җиде процент) дәрәҗәсендә планлаштырыла.

Фаразлау күрсәткечләрен үтәүдә сәнәгать предприятиеләренең өзлексез эшләвен тәэмин итү мөһим фактор булып тора. Шул ук вакытта предприятиеләрнең федераль ярдәм чараларында, шул исәптән,

– импортны алмаштыру буенча;

– яңа продукция эшләү һәм булдыру буенча;

– җитештерү предприятиеләре өчен «Сәнәгать ипотекасы» ташламалы кредит бирү программасы механизмын куллану буенча,

– предприятиеләрне яңа логистика чылбырларына урнаштыру һәм экспорт базарларын диверсификацияләү буенча программалар кысаларында күздә тотылганнарында максималь катнашуын тәэмин итәргә кирәк.

2023 елда авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 280 млрд сум дәрәҗәсендә планлаштырыла.

Агросәнәгать комплексы өлкәсендә фараз күрсәткечләрен үтәүне тәэмин итү факторлары түбәндәгеләр булырга тиеш:

– планлаштырыла торган срокларда авыл хуҗалыгы чималын эшкәртүгә юнәлдерелгән инвестиция проектларын да гамәлгә ашыру һәм эшләтеп җибәрү;

– җитештерелә торган продукцияне арттыру, шул исәптән, федераль ярдәм чараларында катнашу, туфракның уңдырышлылыгын яхшырту, мелиорация комплексын үстерү һәм кулланылмый торган җирләрне авыл хуҗалыгы әйләнешенә кертү хисабына да;

– республикада авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысын формалаштыручы хуҗалык алып баруның кече формаларына алга таба да ярдәм итү һәм аларны үстерү;

– шулай ук, авыл хуҗалыгы оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тулаем күтәрү.

2023 елда ваклап сату әйләнеше 1,3 (Бер бөтен уннан өч) трлн сум дәрәҗәсендә булыр, дип фаразлана.

Аерым чит ил компанияләренең безнең базардан китүе үзебезнең җитештерүчеләргә аларның урыннарын алырга һәм үз товар төркемнәрендә ныклап урнашырга мөмкинлек бирә.

Шулай ук гомуми әйләнештә электрон сәүдә өлешен арттыру тенденциясе дәвам итә.

Ел башыннан республикада маркетплейсларда товар белән тәэмин итүчеләр саны арта.

Республиканың төзелеш комплексында торак, сәнәгать һәм инфраструктура төзелеше күләмнәрен саклау каралган.

Юл төзелешендә зур масштаблы проектларны гамәлгә ашыруны исәпкә алып, әлеге секторның чагыштырма авырлыгы төзелеш структурасында 40 процентган артып китте.

Проектларны гамәлгә ашыру 2025 елга

– беренче категориядәге юлларның озынлыгын икеләтә диярлек арттыруга;

– Идел һәм Чулман елгалары аша ике күперне файдалануга кертүгә ирешергә мөмкинлек бирәчәк.

Торак төзелешендәге фаразлар 2023 елга – 2 млн 830 мең кв. метр торак тапшыруны; өч ел эчендә 8 млн 835 мең кв. метр торак тапшыруны күздә тота.

Фаразның үтәлешен тәэмин итү факторлары булып тора:

– яңа торак комплекслары төзелеше өчен территорияләр әзерләү;

– төзелеш материаллары производствосында импортны алмаштыру;

– юл төзелешендә проектларны тормышка ашыруны дәвам итү;

– шулай ук инвестиция-төзелеш циклын кыскарту.

Хөрмәтле депутатлар!

Фаразлауны тәэмин итүнең төп факторларыннан берсе – инвестиция проектларын гамәлгә ашыру.

2023 елга төп капиталга инвестицияләр күләме буенча куелган план – 782,7 (Җиде йөз сиксән ике бөтен уннан җиде) млрд сум.

Хәзерге шартларда Россия инвесторлары һәм дустанә илләрдән инвесторларның инвестиция активлыгын стимуллаштыру өчен, инвестиция климатын яхшырту буенча даими рәвештә нәтиҗәле эшне дәвам иттерергә кирәк.

Бизнес алып баруның уңайлы шартларын булдыру белән беррәттән, инвестицияләрне стимуллаштыру өчен булган ярдәм чараларын куллану мөһим.

Капитал салуны яклау һәм кызыксындыру механизмын яңадан эшләтеп җибәрүгә юнәлдерелгән федераль законнар агымдагы елның июнь аенда Россия Федерациясе Президенты тарафыннан имзаланды, сентябрьдә Россия Федерациясе Хөкүмәте карары кабул ителде.

Безгә әлеге механизмны кулланырга һәм предприятиеләр белән тиешле килешүләр төзүне башкарырга кирәк.

Әзерлекле инженерлык инфраструктурасы булу инвесторлар өчен кызыктыргыч шарт булып тора. Резидентларны кирәкле инфраструктура белән тәэмин итү инструментларының берсе – 1119 номерлы РФ Хөкүмәте карары кысасында индустрия парклары, сәнәгать технопарклары һәм МИЗ (махсус икътисадый зона) инфраструктурасы объектларын төзү һәм модернизацияләү чыгымнарын каплау.

Хәзерге вакытта Иннополис махсус икътисадый зонасы идарәсендә индустрия паркы һәм югары технологияләр өлкәсендәге парк төзелә һәм Алабуга махсус икътисадый зонасы идарәсендә индустрия паркы төзү планлаштырыла.

Инвестицияләр үсешенең бер факторы булып моношәһәрләр территорияләрендә, шул исәптән алгарышлы үсеш территорияләрендә инвестиция проектларын тормышка ашыру тора.

Моношәһәрләрне үстерү фондының финанслашу программасы ярдәмендә инфраструктура төзелеше һәм Алгарышлы үсеш территориясе (ТОР) резидентларына бирелә торган салым ташламалары 20 меңнән артык яңа эш урыны булдырырга һәм якынча 50 млрд сум инвестиция җәлеп итәргә мөмкинлек бирде.

Агымдагы елда моношәһәрләрне үстерүгә ярдәм итү өлкәсендә федераль үзәк тарафыннан мөһим карарлар кабул ителде:

– ВЭБ.РФның проектларны тормышка ашыруда катнашу Тәртибе һәм төп шартлары расланды;

– ВЭБ.РФ әйләнешендә Моношәһәрләрне үстерү фонды акчалары сакланып калды;

– моннан тыш, Россия моношәһәрләре территориясендә алгарышлы үсеш территорияләренең гамәлдә булу вакыты 2 елга озайтылды.

Моношәһәрләр башлыкларына, тиешле тармак министрлыкларына әлеге аталган инструментларны актив кулланырга кирәк.

Төп бурыч һаман да – барлык муниципаль берәмлекләрдә халыкның мәшгульлеген арттыруны тәэмин итүне үстерү.

Мәшгульлек хезмәтләре, республика муниципаль берәмлекләре белән берлектә, системалы эш алып баруны дәвам иттерәләр: эшсезләрне персональ рәвештә эшкә урнаштыралар, аларны үзмәшгульлеккә җәлеп итәләр, яңадан һөнәри әзерләүне оештыралар.

Агымдагы ел ахырына эшсезләр саны күп дигәндә 15 мең кеше дәрәҗәсендә фаразлана.

Хөрмәтле коллегалар!

Республиканың социаль-икътисадый үсеше фаразын тәэмин итү өчен, кече һәм урта эшкуарлыкка мөһим роль бирелә, 2023 елда икътисадта бу өлкәдә эшләүче кешеләр саны 804 меңнән артык булырга тиеш.

Максатчан параметрларга ирешүгә юнәлдерелгән факторларның берсе – кече һәм урта эшкуарлыкка дәүләт ярдәме чаралары.

Муниципалитетларның һәм бизнес-берләшмәләрнең бурычы:

– эшкуарларны мөмкин булганча федераль һәм республика чараларына җәлеп итү максатында адреслы эшне дәвам иттерү.

Әлеге чараларның нәтиҗәлелеге саннар белән раслана. Без агымдагы елда ярдәм алган республика предприятиеләре эшчәнлегенә анализ ясадык, аларда мәшгульләр саны, уртача айлык хезмәт хакы һәм чыгарылган продукция буенча күрсәткечләр арту күзәтелә.

Безнең бурыч – эшкуарларның ярдәм чараларын вакытында алуы.

Үзмәшгульләр институты кече һәм урта эшкуарлык субъектларының эш белән тәэмин ителеше саны буенча планны үтәүгә зур өлеш кертә.

Муниципалитетларның бурычы:

– КУЭ (кече һәм урта эшкуарлык) илкүләм проекты кысасында гамәлгә ашырыла торган ярдәм чараларына үзмәшгульләрне максималь рәвештә җәлеп итүне тәэмин итү;

– республиканың шәһәр һәм районнарында үзмәшгульләр өчен махсус ярминкәләр уздыруны дәвам иттерү.

Җитештерелә торган продукциягә ихтыяҗны Республика маркетинг үзәге аша стимуллаштыру кече һәм урта бизнес үсеше өчен тагын бер мөһим факторы булып тора.

Агымдагы елның 9 ае йомгаклары буенча, әлеге ресурс ярдәмендә 3,5 меңнән артык кече һәм урта эшкуарлык субъекты якынча 130 млрд сум табыш алды.

Эш белән тәэмин итү үсешенең төп резервы булып, муниципаль сәнәгать паркларын үстерү тора.

Беренче яртыеллыкта, республика салым ташламаларыннан файдалануны исәпкә алып, сәнәгать паркларын үстерүнең гамәлгә ашырыла торган концепциясе нәтиҗәсендә, аларның тулылануында үсеш күзәтелә, яңа резидентлар җәлеп ителә, эшләүчеләр саны арта.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановның Юлламасы нигезендә, фаразлау чорында муниципалитетлар һәм республиканың алдынгы сәнәгать парклары идарәче компанияләре белән безнең уртак бурыч – уңышлы тәҗрибәне тарату, муниципаль парклар үсешен тоткарлаучы факторларны бетерү буенча чараларны, шул исәптән, идарәче компаниянең һәм җирле үзидарә органнарының резидентларны һәм инвестицияләрне җәлеп итү буенча тиешле йөкләмәләре нигезендә гамәлдәге инженерлык инфраструктурасын үстерүгә һәм модернизацияләүгә юнәлдерелгәннәрен дә гамәлгә ашыру.

Бу максатлар өчен киләсе елда өстәмә финанслау планлаштырыла.

Моннан тыш, 2023 елда кече һәм урта бизнеска ярдәм чараларына өстәмә рәвештә әлеге ярдәм чараларының кирәклеге һәм нәтиҗәлелеге белән бәйле рәвештә микрозаемнарны һәм поручительлекләрне финанслауны күздә тоту планлаштырыла.

Алда торган бурыч: күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында максималь рәвештә мәгълүмат бирү һәм аларның бизнес өчен нәтиҗәлелеген тәэмин итү.

Хөрмәтле депутатлар!

Билгеләнгән бурычларны тормышка ашыру социаль тотрыклылыкны һәм халыкның иминлеген тәэмин итү өчен нигез булып тора.

2023 елга реаль хезмәт хакының 102% дәрәҗәсендә артуы планлаштырыла.

Муниципаль берәмлекләргә табышларны легальләштерү һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча тиешле чаралар күрү буенча ведомствоара комиссияләр эшчәнлеге кысасында максатчан параметрларга ирешүне тәэмин итү эшен дәвам иттерергә кирәк.

Шулай ук хезмәт хакы тармак һәм тулаем район буенча уртачадан түбән булган оешмаларга да игътибар итү мөһим.

Илкүләм проектлар чараларын гамәлгә ашыру республиканың социаль-икътисадый үсешенә куелган максатларга ирешүнең мөһим инструментларыннан берсе булып тора.

2022 елда Татарстан Республикасында 13 илкүләм проект кысаларында 49 төбәк проекты гамәлгә ашырыла, аларга 36,5 млрд сум күләмендә лимит билгеләнде.

Бүген илкүләм проектларны тормышка ашыру кысасында түбәндәгеләрне башкарырга кирәк:

– дәүләт контрактлары төзү буенча эшне төгәлләргә;

– федераль бюджеттан бүлеп бирелгән акчаларны үзләштерү темпларын арттырырга;

– эшләрне башкару, җиһазлар китерү һәм хезмәтләр күрсәтүнең үз вакытында башкарылуын контрольдә тотарга;

– республикабыз халкының тормыш сыйфатының 165 күрсәткече буенча максатчан күрсәткечләрнең үтәлешен тәэмин итәргә.

Фаразлар буенча куелган бурычларга ирешү максатларында, республика дәүләт хакимиятенең илкүләм проектларны тормышка ашыруда катнашучы барлык башкарма органнары тарафыннан илкүләм проектларның максатчан күрсәткечләрен билгеләү һәм 2023–2025 елларга республиканың социаль-икътисадый үсешенең фаразланган параметрларын тәэмин итә торган тиешле финанслау бүлеп бирү буенча федераль проект офислары белән эш алып барыла.

Хөрмәтле депутатлар!

2023–2025 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешен фаразлауның төп параметрлары менә шундый.

Үз Юлламасында Татарстан Республикасы Президенты билгеләгән бурычларны үтәүне тәэмин итү, фаразланган параметрларга ирешү өчен, республиканың барлык дәрәҗәдәге хакимият органнарының, предприятиеләрнең һәм оешмаларының килешенгән һәм координацияләнгән эшләве, аларны чишү юлларын эзләүдә һәм икътисадый үсеш резервларын ачыклауда килеп туган проблемаларга оператив җавап бирүе кирәк.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ БЮДЖЕТ, САЛЫМ ҺӘМ ФИНАНС КОМИТЕТЫ РӘИСЕ ЛЕОНИД ЯКУНИН ЧЫГЫШЫ

**Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проекты Бюджет кодексында каралган барлык күрсәткечләргә дә җавап бирә.**

Бүген без өчьеллык чорга бюджет проекты хакында фикер алышуны дәвам итәбез. Алдан каралган процедураларның барысы да тәмамланды. Зона киңәшмәсендә, парламент тыңлауларында, Дәүләт Советы комитетларында фикер алышуда төрле структураларның, иҗтимагый оешмаларның меңгә якын вәкиле, шулай ук гражданнар да катнашты. Закон проектына карата күп кенә сораулар һәм аларга җаваплар булды. Шулай ук проект Дәүләт Советы сайтына да урнаштырылды. 2023 елгы бюджетта бюджет сәясәтенең түбәндәге төп бурычлары каралганны билгеләп үтәм:

– республика бюджет системасының баланслылыгы һәм тотрыклылыгы;

– социаль йөкләмәләрне үтәү;

– илкүләм проектларны һәм дәүләт программаларын гамәлгә ашыру.

Өчьеллык чорга бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрендә гамәлдәге салым ташламаларын саклап калу, салым салуның яңа режимнарын (автоматлаштырылган гадиләштерелгән система) һәм салым түләүләрен түләүнең яңа тәртибен кертү каралган. Алдагы өчьеллык чорда, гамәлдәге санкция чикләүләрен һәм бюджет керемнәренең үз чыганакларын булдыруны исәпкә алып, чыгымнарны оптимальләштерү чараларын зур күләмдә үткәрүгә әзер булырга кирәк һәм бу дәүләт органнарына, муниципаль берәмлекләргә аерым җаваплылык йөкли. Проектны анализлау бюджет классификациясенең барлык бүлекләре буенча бюджет чыгымнарының агымдагы ел бюджеты турындагы иң элек расланган закон саннарына карата артуын күрсәтә.

Закон проектының программа рәвешендә формалаштырылган булуы һәм кирәкле ресурслар белән тәэмин ителүе республика территориясендә гамәлгә ашырыла торган региональ проектларның күрсәткечләренә ирешергә ярдәм итә. Социаль әһәмияткә ия чыгымнар һәм агымдагы чыгымнар арттырылган һәм 2023 елга алар чыгымнарның гомуми күләменнән якынча 80% тәшкил итәчәк.

Татарстанда яшәүчеләргә акчалата һәм натуралата рәвештә гамәлдәге социаль ярдәм чаралары (пенсияләргә өстәмәләр, җәмәгать транспортында йөрүгә, торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә ташламалар, дарулар белән тәэмин итү һәм башкалар) күрсәтүне тәэмин итүгә, шулай ук бу чараларны киңәйтүгә дә акча каралган.

Бюджет проектында медицина хезмәткәрләренә, педагогик, социаль хезмәткәрләргә, мәдәният учреждениеләре персоналына, фәнни хезмәткәрләргә һәм бюджет өлкәсенең башка категория хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне ел саен арттыруга финанслар каралган.

Кешеләрнең яшәү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән илкүләм проектларны гамәлгә ашыру бюджетның чыгым өлешенең өстенлекле юнәлеше булып кала.

Хөрмәтле депутатлар!

Чыгышымны йомгаклап, шуны билгеләп үтәм:

Аерым депутатлар мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаиләләре белән очрашты, аларга финанс ярдәме һәм социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләре барлыгы ачыкланды. Аларны хәл итү максатларында ашыгыч һәм кичектергесез чыгымнар өчен, шул исәптән махсус хәрби операциягә бәйле булганнары өчен дә, Республика Хөкүмәте Резерв фондын арттыруны күздә тотарга кирәк дип саныйбыз. Тулаем алганда, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджет тулы күләмдә агымдагы мәсьәләләргә җавап бирә, баланслы булып тора һәм безнең гамәлдәге йөкләмәләрне, илкүләм максатларны исәпкә ала. Финанс тотрыклылыгына ирешү һәм икътисадны яңа шартларга яраклаштыру буенча күрелгән барлык чаралар санкцияләрнең тискәре тәэсирен һәм аларның икътисад үсешенә йогынтысын киметергә ярдәм итәчәк.

Бюджет Юлламасына Хисап палатасы, Дәүләт Советы Хокук идарәсе, прокуратура һәм Иҗтимагый палатаның уңай бәяләмәләре бар, шулай ук закон проекты Дәүләт Советының барлык комитетлары тарафыннан хупланды.

Хөрмәтле депутатлар, Сездән комитет карарын хуплауны һәм закон проектын беренче укылышта кабул итүне үтенәм.

Төзәтмәләр кертү вакытының агымдагы елның 28 октябренә кадәр билгеләнүенә игътибар итүегезне үтенәм.

Төзәтмәләрне катгый рәвештә Дәүләт Советы Регламенты 100 статьясының 3 өлеше нигезендә формалаштыруны да исәпкә алырга кирәк.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЫ РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИН ЧЫГЫШЫ

**Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 нче, республика Бюджет кодексының 61 нче маддәләре нигезендә, Президент тарафыннан, Дәүләт Советына киләсе 2023 елга һәм 2024–2025 еллар план чорына бюджет турында закон проекты кертелде.**

Татарстан Республикасының бюджет турындагы закон проекты Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының Бюджет кодекслары тарафыннан куелган таләпләргә туры китереп әзерләнде.

Закон проектын **23 маддә һәм 41 кушымта** тәшкил итә. Бюджет кодексы тарафыннан каралган барлык документлар һәм материаллар да әзерләнде. Аларда бюджет формалаштыру барышын тулысынча чагылдырган мәгълүматлар җыелган.

Бюджетны формалаштыру бер үк вакытта ике юнәлештә, ягъни керемнәр һәм чыгымнар өлешендә алып барылды.

Керемнәр күләмен санаганда, без Финанс министрлыгы, Икътисад министрлыгы, Салым хезмәте, тармак министрлыклары, оешмалар белән бергә аерым салым фаразларын исәпләдек. Шулай ук җирле бюджетларның керемнәре буенча муниципаль берәмлекләрнең тәкъдимнәре дә каралды.

Бюджетның чыгым өлешен әзерләү барышында республиканың министрлыклары һәм идарә тармаклары, муниципаль районнар һәм шәһәр берәмлекләре белән киңәшмәләр уздырылды.

Башкарылган уртак һәм бердәм эш нәтиҗәсендә, бюджет акчасын төп бүлүчеләр һәм муниципаль берәмлекләр белән сценар шартларда бюджет фаразы каршылыкларсыз килештерелде.

Шулай итеп, 2023–2025 елларга Татарстан Республикасы бюджеты, 45 муниципаль район һәм шәһәр берәмлеге, 911 авыл җирлегенең бюджет фаразлары төзелде.

Алга таба – **бюджет керемнәре** турында.

Бюджетның керем өлешен формалаштыру республикабызның Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнгән Татарстан Республикасының социаль-икътисади үстерүнең төп күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырылды.

Бер үк вакытта, бюджетны әзерләгәндә федераль законнардагы үзгәрешләрне дә исәпкә алдык.

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан куелган республика икътисадына инвестицияләр җәлеп итү бурычын үтәү өчен, керемнәр буенча бюджет проектында гамәлдәге салым ташламалары һәм кайберләренең планлаштырылган чорда дәвам итүе исәпкә алынды.

Өчьеллык чорга **бюджетның керем чыганаклары** хакында.

**Табышка салым** керемнәрен бәяләгән вакытта Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматларының «Табыш» күрсәткеченең күләм фаразы кабул ителде. Шулай ук республиканың эре һәм уртача оешмалары мәгълүматлары, салым хезмәте хисаплары һәм 2022 елның узган чорына салым җыелу динамикасы файдаланды. Табышка салымның гомуми күләменнән якынча 60 процентын тәэмин итүче предприятиеләр белән очрашулар үткәрелде.

Нәтиҗәдә 2023 елда табышка салым 103,1 млрд сум күләмендә планлаштырыла.

**Физик затларның кеременә салым** Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына 116,8 млрд сум күләмендә фаразлана. Республика бюджетына керемнәр 81,9 млрд сум тәшкил итәчәк. Салым буенча исәпләүләрне башкарганда Икътисад министрлыгы тарафыннан фаразланган хезмәткә түләү фонды, агымдагы елда керемнәрнең көтелүче күләмен һәм аның үсешен нигез итеп алдык.

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына **акцизлар** кереме фаразы – 37,9, ә республика бюджетына 36,6 млрд сум тәшкил итә.

**Оешмаларның мөлкәтенә салым.** 2023 елда аның буенча керемнәр 31,2 млрд сум күләмендә фаразлана. Планлаштырган вакытта төп капиталга инвестицияләр фаразы, салым хисабы мәгълүматлары исәпкә алынды.

**Җир салымы** – муниципаль берәмлекләр бюджетлары өчен әһәмиятле керем чыганагы. Салым буенча фаразны төзегәндә салым хезмәтләренең хисапларын исәпкә алдык һәм, әлбәттә, саннарны барлык муниципаль районнар һәм шәһәр берәмлекләре белән дә килештердек. Җир салымы кереме ел саен 8,3 млрд сум күләмендә фаразлана.

**Транспорт салымы** кереме 2023 елда 6,6 млрд сум күләмендә бәяләнә. Керемнәрне исәпләгән вакытта салым хисабы һәм берничә ел дәвамында җыелу күрсәткечләре исәпкә алынды. Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә транспорт салымы фаразланган күләмдә юл фондына күчереләчәк.

**Бердәм керемгә салым** берләштерелгән бюджетка – 23,5, республика бюджетына 15,7 млрд сум күләмендә фаразлана.

Тулысынча муниципаль берәмлекләрнең бюджетларына керүче **физик затларның милкенә салым** 2023 елда 2,6 млрд сум күләмендә бәяләнә.

Берләштерелгән бюджетның фаразланучы **салым булмаган керемнәре** күләме – 11,2 млрд сум, республика бюджетыныкы – 6,1 млрд сум. Бу күләмгә җир һәм милекне арендага бирүдән һәм сатудан, штрафлардан, экологик түләүләрдән һәм башкалардан табышлар керә.

Федераль бюджеттан **кайтарылмый торган керемнәр** Татарстан Республикасы бюджеты проектында 2023 елга 51,9 млрд сум күләмендә исәпләнгән.

**Алга таба – бюджет чыгымнары турында.**

Берләштерелгән бюджетның чыгымнар күләмен санаганда, без федераль һәм республика дәрәҗәсендәге, бүгенге көндә гамәлдә булган законнарга һәм норматив хокукый актларга нигезләндек. Чыгымнар Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт Советына Юлламасында куйган бурычларны тормышка ашыруга йөз тота.

Бюджет чыгымнарын сыйфатлаучы аерым юнәлешләрне билгеләп узам.

Беренче чираттагы, социаль әһәмиятле һәм агымдагы чыгымнар күләме елдан-ел арта бара. 2023 елга фаразланган бюджетта алар чыгымнарның барлык күләменнән 80 процентын тәшкил итәчәк.

Чыгым өлешен санаганда, бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын арттыруга акча тулы күләмдә каралды.

Чыгымнарны дәүләт программалары буенча бүлү дәвам итә. Бюджет чыгымнарының программалар белән тәэмин ителгән өлеше –88%. Дәүләт программалары төзелешендә илкүләм һәм федераль проектлар чагылыш тапты.

Социаль әһәмияткә ия булган республика чаралары инде берничә ел уңышлы финанслана. Киләсе елларда да бу мөһим эш дәвам итәчәк. Әлеге чыгымнарның гомуми күләме 2023 ел бюджетында 7,3 млрд сум күләмендә фаразлана.

**Алга таба бюджет чыгымнарының кайсы юнәлешләргә бирелүе хакында тулырак мәгълүмат китерәм.**

Бюджет классификациясе нигезендә бюджетның чыгым өлеше **«Гомумдәүләт мәсьәләләре»** бүлегеннән башлана. Бүлек буенча 2023 елга берләштерелгән бюджет чыгымнары – 42,5 млрд сум, республика бюджеты буенча 36 млрд сум фаразлана. Бу бүлеккә Хөкүмәтнең резерв фонды чыгымнары; идарә аппаратын, Фәннәр академиясен, архивларны, мировой судьяларны тоту, авыл җирлекләренә грантлар тапшыру керә.

**«Милли оборона»** бүлеге буенча республика бюджеты чыгымнары 167,8 млн сум тәшкил итәчәк.

**«Милли куркынычсызлык һәм хокук саклау эшчәнлеге»** бүлеге буенча берләштерелгән бюджет чыгымнары – 2,4, республика бюджетында – 1,7 млрд сум. Әлеге бүлектә Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгын, аның чараларын, муниципаль берәмлекләрнең бердәм диспетчер хезмәтләренең эшен финанслау һәм башка чыгымнар күздә тотыла.

Берләштерелгән бюджет буенча барлыгы – 89,9, республика бюджеты буенча 88,4 млрд сум белән **«Милли икътисад»** бүлеге үз эченә бер төркем тармакларны колачлый. Алар арасында иң зурлары – юл хуҗалыгы, капиталь характердагы чыгымнар, авыл хуҗалыгы, транспорт.

**«Торак-коммуналь хуҗалык»** бүлегенең чыгымнары берләштерелгән бюджетта – 26,6, республика бюджетында 16,8 млрд сум күләмендә фаразлана.

**«Әйләнә-тирә мохитне саклау»** бүлегенең чыгымнары барлыгы – 2,9 млрд сум, республика бюджеты буенча 2,7 млрд сум күләмендә фаразлана. Әлеге чыгымнар табигатьне саклау чараларын гамәлгә куюга, Экология министрлыгы аппаратын, идарә тармагы учреждениеләрен тәэмин итүгә тотыла.

**Бюджет чыгымнарының иң эре бүлеге – «Иҗтимагый-мәдәни өлкә».**

Иҗтимагый өлкә чыгымнары күләме бу юнәлештә ел саен үсеш динамикасы барлыгын күрсәтә. Социаль өлкә чыгымнары берләштерелгән бюджетта 2022 ел белән чагыштырганда 2025 елда 24 процентка үсә.

Иҗтимагый-мәдәни өлкәдә **«Мәгариф»** тармагы чыгым күләме буенча шактый зур. 2023 елда чыгымнар күләме берләштерелгән бюджетта – 128,6, республика бюджетында 78,4 млрд сум тәшкил итәчәк.

Бу акча исәбенә өстәмә рәвештә мәгариф учреждениеләренең яңа челтәре, укучылар контингенты артуы, кадет интернатларында тәрбияләнүчеләрне тоту, йомгаклау аттестациясен уздыруга чаралар керә.

«Мәгариф» тармагында республиканың бер төркем максатчан программалары финанслана. Алар арасында Татарстан Республикасында телләрне саклау һәм үстерү, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру, белем бирү учреждениеләренә капиталь ремонт ясау, ресурс үзәкләрен булдыру программалары да бар.

**«Сәламәтлек саклау» бүлеге.** Мәҗбүри медицина иминияте чараларын исәпкә алып, сәламәтлек саклауны тотуга һәм үстерүгә чыгымнарның гомуми күләме – 97,1 млрд сум, шул исәптән республика бюджетыннан 39,2 млрд сум тәшкил итәчәк.

Республика бюджетының сәламәтлек саклау өлкәсе чыгымнары эченә югары технологияле ярдәм, тармак учреждениеләрен тоту, даруларны һәм җиһазларны үзәкләштереп сатып алу, гемодиализ процедураларын уздыру, мәҗбүри медицина иминиятләштерү системасы аша медицина оешмаларын бер канал аша финанслау чыгымнары керә.

Тагын бер тармак – **«Социаль сәясәт».** Гомуми чыгымнар биредә берләштерелгән бюджетта – 57,7, республика бюджетында 57,5 млрд сум күләмендә фаразлана. Быел бирелүче барлык социаль пособиеләр һәм түләүләр инфляциягә карата арттырып саналган.

Социаль өлкәнең тагын бер бүлеге – **«Мәдәният, кинематография»гә** 2023 елга берләштерелгән бюджетта – 18,6, республика бюджеты буенча 10,6 млрд сум күләмендә акча каралган. Чараларны грантлар тапшыруга, китап фондларын туплауга, иҗади берләшмәләргә ярдәмгә, музейларны, театрларны, китапханәләрне, иҗади коллективларны тотуга юнәлтергә планлаштырыла.

**«Физик культура һәм спорт»** бүлеге буенча чыгымнар берләштерелгән бюджетта – 10,3, республика бюджеты буенча 4,4 млрд сум тәшкил итә. Акчаны спорт әзерлеге учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүгә, массакүләм спорт һәм спортта югары ирешүләр өлкәсендә чараларны оештыруга һәм уздыруга юнәлдерү планлаштырыла.

2023 елга республика бюджетының **«Массакүләм мәгълүмат чаралары»** бүлеге чыгымнары – 1,7 млрд сум, шул исәптән телерадиотапшыруларга – 992 млн сум, басма матбугатка һәм нәшриятка 703 млн сум күләмендә фаразлана.

**«Муниципаль берәмлекләр бюджетларына гомуми характердагы бюджетара трансфертлар»** бүлеге буенча республикада дотацияләр һәм башка гомуми характердагы бюджетара трансфертлар каралган, аларның гомуми күләме – 22,9 млрд сум.

**«Дәүләт һәм муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү»** бүлегенең чыгымнары берләштерелгән бюджетта – 853,7 млн сум, республика бюджеты буенча 529,5 млн сум тәшкил итәчәк.

Шулай итеп, 2023 елга **берләштерелгән бюджетның** керем өлеше – 394,4 млрд сум, чыгым өлеше 421,5 млрд сум фаразлана, дефициты – 27,1 млрд сум; **республика бюджетының** керем өлеше – 333,9, чыгым өлеше 361 млрд сум фаразлана, дефициты – 27,1 млрд сум.

2023 елга, 2024 һәм 2025 елдагы план чорына бюджет проекты Дәүләт Советы комитетлары утырышларында, парламент тыңлауларында, республиканың барлык район һәм шәһәр берәмлекләре белән киңәшмәдә тикшерелде.

Бюджетның төрле дәрәҗәләрдә җентекләп каралуын исәпкә алып, хөрмәтле депутатлардан закон проектын хуплап, аны беренче укылышта кабул итүләрен сорыйм.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХИСАП ПАЛАТАСЫ РӘИСЕ УРЫНБАСАРЫ АЛЬБЕРТ ВӘЛИЕВ ЧЫГЫШЫ

**2023 елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проекты закон таләпләренә туры килү-килмәү буенча экспертиза узды.**

Бәяләмә әзерләгәндә, Хисап палатасы фаразланган параметрларның нигезлелеге һәм керемнәр һәм чыгымнарны чагылдыруның тулылыгы мәсьәләләрен карады. Хисап палатасы мөрәҗәгате буенча Финанс министрлыгы һәм керемнәрнең аерым администраторлары тарафыннан өстәмә тапшырылган белешмәләр кулланылды. Кире кайтарылмый торган кертемнәр күләмнәрен бәяләү максатында 2023 елга федераль бюджет проекты күрсәткечләре анализланды.

Тәкъдим ителгән бюджет проектында Хөкүмәтнең Резерв фонды бюджет законнары белән билгеләнгән барлык чикләүләре, аерым алганда, дәүләт бурычы һәм аңа хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме, дефицит (кытлык) күләме буенча, үтәлгән.

Бүген карала торган Закон проекты Бюджет кодексы нигезләмәләренә һәм аларны үтәү өчен кабул ителгән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы актларына туры килә. Редакцияләү белән бәйле берничә төзәтмә кертү кирәклеге турында Финанс министрлыгына хәбәр ителде.

2023 елга төп салым керемнәре буенча күрсәткечләр республиканың социаль-икътисадый үсеше фаразын, салым һәм бюджет законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырылган.

2022 елга бюджетның чагыштырма – беренчел расланган күрсәткечләре белән чагыштырганда, төп салымнар буенча кертемнәр күләме артуы фаразлана: табышка салым буенча – 14,3 процентка, НДФЛ буенча – 25 процентка.

Дөнья энергетика базарында бәя конъюнктурасы белән бәйле системалы чикләүләр, тышкы ихтыяҗ кимү, агымдагы ел нәтиҗәләре буенча көтелгән күрсәткечләр белән чагыштырганда, аерым керем чыганакларының планлаштырылучы күләмнәренә билгеле бер йогынты ясый.

Фаразланган күрсәткечләр арткан очракта өстәмә керемнәрдән файдалануның бюджет законнары белән билгеләнгән механизмнары җәлеп ителәчәк.

Шулай ук керемнәргә карата түбәндәгене билгеләп үтәм. Россия Федерациясе Хисап палатасы алдагы чорга федераль бюджет проектына Бәяләмәсендә аларны арттыруның потенциаль резервлары күрсәтелгән һәм, беренче чиратта, бюджетка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларны түләү хисабына. Россия буенча бу – өч миллиард җиде йөз җитмеш биш миллион сум, Татарстан буенча республика бюджетына күчерелә торган табышка салым, региональ салымнар һәм җыемнар буенча түләүләрне җыеп ала алмау күләме якынча ике миллиард җиде йөз миллион сум тәшкил итә.

Керемнәрнең гомуми күләмендә федераль бюджеттан кире кайтарылмый торган кертемнәр өлеше 15,5% тәшкил итә.

Киләсе елда көтелгән трансфертлар күрсәткеченә түбәндәге фактор йогынты ясый – беренче бала туу белән бәйле социаль айлык түләүләрне башкару бюджеттан тыш федераль дәүләт фондына тапшырылган. Агымдагы елда бу түләүләр Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары аша башкарылды, республика бюджетында 4 миллиард 180 миллион сум каралган. Шулай итеп, чагыштырма күрсәткечләрдә трансфертларның гомуми күләме кимеми, аерым юнәлешләр буенча үсеш күзәтелә.

Шулай ук 2023 елга бюджет проектында яңа юнәлешләргә максатчан чаралар планлаштырылган. Аерым алганда: хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә һәм вакытлыча эшкә урнашуны оештыруга, җәмәгать эшләрен оештыруга, гомуми белем бирү оешмаларында яңа урыннар булдыруга.

Тулаем алганда, алдагы еллардагы кебек үк, кире кайтарылмый торган кертемнәр буенча күрсәткеч тә иң соңгысы түгел.

2023 елга федераль бюджет проектында Татарстан Республикасы агымдагы елда трансфертлар ала торган шул ук юнәлешләр буенча Россия Федерациясе субъектлары арасында өч йөз илле дүрт миллиард сумнан артык акча бүленмәгән.

Алдагы еллардагы кебек үк, бюджет социаль юнәлешле булуы белән дә характерлана – гражданнарга ярдәм күрсәтү чаралары сакланып калган, капитал салуның төп күләме социаль инфраструктураны үстерү максатына каралган.

Республика муниципаль берәмлекләре белән бюджетара мөнәсәбәтләрне финанс ягыннан тәэмин итү агымдагы ел дәрәҗәсенә карата тулаем алганда биш миллиард җиде йөз унбиш миллион сумга, ягъни 9,7 процентка арта.

Закон проектының чыгым өлеше эчтәлеге гамәлгә ашырыла торган илкүләм проектлар һәм Татарстан Республикасының дәүләт программалары бурычларын хәл итүгә һәм максатларга ирешүенә буйсындырылган.

Бюджет чыгымнарының программа өлеше республиканың гамәлдәге 32 дәүләт программасы чараларын үтәүгә ассигнованиеләрне үз эченә ала.

Хисап палатасы, планлаштырылган бюджет ассигнованиеләрен исәпкә алып, 25 программага төзәтмә кертергә кирәклеген билгеләп үтә, алар, мәсәлән, сәламәтлек саклау; мәгариф һәм фән; авыл хуҗалыгы программалары буенча һәм тагын 12 дәүләт программасы буенча арттырылган.

Дәүләт программалары проектларына һәм аларга кертелә торган үзгәрешләргә экспертиза ясау вәкаләтләрен гамәлгә ашырып, агымдагы елда Хисап палатасы республика Хөкүмәтенә 41 бәяләмә тәкъдим итте. Бу уртак эшнең максаты булып, акчаны формаль үзләштерү куркынычларын бетерү, шулай ук финанслау юнәлешләренең ачыклыгын арттыру һәм конкретлаштыру максатларында бүлеп бирелә торган ресурслар күләменә карап, көтелгән нәтиҗәләрне үз вакытында актуальләштерү юлы белән, бюджет ассигнованиеләрен нәтиҗәле файдалану өчен шартлар тудыру тора.

Хөрмәтле депутатлар!

Хисап палатасының сезнең кулдагы бәяләмәсендә керемнәр һәм чыгымнар, бюджетара мөнәсәбәтләрне финанс белән тәэмин итү, һәрбер дәүләт программасын гамәлгә ашыруга ассигнованиеләр, дәүләт бурычы структурасы, дефицитны (кытлыкны) финанслау чыганаклары буенча тулы мәгълүмат бар.

Чыгышымны тәмамлап, шуны билгеләп үтәм:

1. Беренче укылышта карауга тәкъдим ителгән Закон проекты бюджет проектын формалаштыру һәм аның эчтәлеге таләпләренә җавап бирә.
2. 2023 елга республика бюджеты балансланган. Фаразлана торган керемнәр һәм кытлыкны финанслау чыганакларыннан кертемнәр күләме планлаштырылган чыгымнарның үтәлешен тулысынча тәэмин итә.
3. Дефицитны (кытлыкны) финанслауның Закон проекты тәкъдим итә торган чыганаклары составлары буенча бюджет законнарына туры килә.
4. Финанс министрлыгы мәгълүматларына караганда, бюджет проектының төп параметрларына йогынты ясамый торган редакцион характердагы кайбер мәсьәләләрне Закон проектын икенче укылышка әзерләгәндә хәл итү планлаштырыла.

# КОТЛЫЙБЫЗ!

2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә мөһим өлеш кертүе өчен «Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы баш тренеры **Апельганец** Валентина Андреевна **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүе өчен «Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры **Насыйбуллин** Рөстәм Илһам улы, 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында җиңү яулавы өчен «Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторы, капитан **Осипова** Ирина Николаевна, халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары, сәламәтлек саклау өлкәсенә югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең профессор В.С. Груздев исемендәге акушерлык һәм гинекология кафедрасы мөдире **Фәткуллин** Илдар Фәрит улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүе өчен «Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы тренеры **Арутюнян** Эдик Хачатурович, 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында җиңү яулаганнары өчен «Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторлары: сакчы **Макагонова** Екатерина Валерьяновна, ярымсакчы **Петрова** Олеся Константиновна, капкачы **Яшина** Ангелина Павловна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында җиңү яулаганнары өчен «Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы спортчы-инструкторлары: ярымсакчы **Ованесова** Мария Юрьевнага; сакчы **Тыртышная** Яна Михайловнага, һөҗүмче **Юшкова** Даяна Азат кызына, 2022 ел сезоны суперлигасы чирәмдә хоккей буенча хатын-кыз командалары арасында Россия чемпионатында спортчыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә зур өлеш кертүе өчен «Ак Барс-Динамо» «чирәмдә хоккей клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы тренеры **Салова** Елена Николаевнага **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ

(843) 222-09-65, 222-09-70.

E-mail: vtreklama@mail.ru

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы Конституция судын бетерү, Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясе суд системасы турында» 1996 елның 31 декабрендәге 1-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон, «Аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 декабрендәге 7-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон (алга таба – «Аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» Федераль конституциячел закон), «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-I номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законы), Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судын бетерүгә бәйле мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Татарстан Республикасы Конституция судын бетерү**

Татарстан Республикасы Конституция суды 2022 елның 31 декабрендә бетерелә.

3 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вәкаләтләрен туктату**

1. «Аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» Федераль конституциячел закон үз көченә кергән көнгә гамәлдә булган Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вәкаләтләре 2022 елның 30 декабрендә туктатыла. Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының вәкаләтләрен туктату турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.

2. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә вәкаләтләре туктатылган Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы отставкага киткән дип санала.

3. Әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына, шулай ук вәкаләтләрен үтәүне элегрәк туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына таныклыклар тапшырыла. Таныклыкны тапшыру тәртибе һәм аның тасвирламасы турында нигезләмә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана.

4 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына һәм Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратының дәүләт граждан хезмәткәрләренә гарантияләр**

1. Әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына, шулай ук вәкаләтләрен үтәүне элегрәк туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына (алга таба – Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясы) Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьялары өчен каралган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында билгеләнгән гарантияләр (матди һәм социаль тәэминатны да кертеп) саклана.

2. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясына үзенең теләге буенча йә гомуми нигезләрдә пенсия, йә салым салынмый торган ай саен гомерлек акчалата түләү билгеләнә.

3. Әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә вәкаләтләрен үтәүне туктаткан Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына ай саен гомерлек акчалата түләү ул киткән вазыйфа буенча «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә исәпләнә торган айлык акчалата бүләкләүнең 80 проценты күләмендә билгеләнә. Судья булып эшләү стажы 15 елдан артыграк булган отставкадагы судьяга ай саен гомерлек акчалата түләү түбәндәгеләрдән чыгып арттырыла: 15 елдан артыграк эш стажының һәрбер елы өчен – күрсәтелгән бүләкләүнең бер проценты күләмендә, ләкин барлыгы ул киткән вазыйфа буенча айлык акчалата бүләкләүнең 85 процентыннан артык түгел. Гыйльми дәрәҗә яисә гыйльми исем, «Россия Федерациясенең атказанган юристы» мактаулы исеме өчен өстәмә түләү алу хокукы булган судьялар өчен ай саен гомерлек акчалата түләү күләме, бу өстәмә түләүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының отставкага чыккан көненә билгеләнгән айлык акчалата бүләкләүнең 85 процентыннан артыграк була алмый. Монда Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вазыйфасында ай саен гомерлек акчалата түләүне санаганда исәпкә алына торган эш стажына Россия Федерациясе судьясы вазыйфасында эшләү вакыты, судлар аппаратларында биләү өчен югары юридик белем таләп ителә торган вазыйфаларда элек эшләү, шулай ук прокурор, тикшерүче, адвокат булып эшләү вакыты кертелә.

4. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясына ай саен гомерлек акчалата түләү федераль законнарда гомуми юрисдикциядәге федераль судлар судьялары өчен каралган нигезләр буенча туктатыла, бетерелә.

5. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкага киткән судьясына «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә эштән киткәндә бирелә торган пособие түләнә.

6. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьяларына гарантияләр бирү тәртибе Татарстан Республикасы Президенты указы белән билгеләнә.

7. Татарстан Республикасы Конституция суды аппаратының Татарстан Республикасы Конституция суды бетерелүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә дәүләт граждан хезмәте турында законнарда билгеләнгән дәүләт гарантияләре тәэмин ителә.

5 статья. **Татарстан Республикасы Конституция судын юридик зат буларак бетерү чараларын уздыру**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судын юридик зат буларак бетерү чараларын уздыруны тәэмин итә.

6 статья. **Әлеге Законны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү**

Әлеге Законны гамәлгә ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7 статья. **«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы беренче өлешенә (2004 елның 28 июлендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 6; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция судында,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

8 статья. **«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3; 2016, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның беренче өлешендәге 3 пунктында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 10 статьяның беренче өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенең,» сүзләрен төшереп калдырырга.

9 статья. **«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 3 өлешендә «, Татарстан Республикасы Конституция суды» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 23 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 26 статьяда «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 27 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенә,» сүзләрен төшереп калдырырга.

10 статья. **Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 һәм $97^4$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 61 статьяның 4 пунктындагы унсигезенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) $97^4$ статьяның $2^1$ пунктындагы алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе,» сүзләрен төшереп калдырырга.

11 статья. **«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 1 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

12 статья. **«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

2) $9^1$ статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларыннан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 14 статьяда:

а) 2 өлешнең беренче абзацында «(Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларыннан тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 6 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

13 статья. **«Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе турында» 2010 елның 30 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 7 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 3), «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

14 статья. **«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 12 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8; 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктында «Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 13 статьяда:

а) 1 өлешнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы Конституция судына,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә «Татарстан Республикасы Конституция судына,» сүзләрен төшереп калдырырга.

15 статья. **«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында**

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясындагы 4 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 4; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 79 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), «һәм Конституция» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

16 статья. **«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» 2013 елның 5 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 3 өлешендә «, Татарстан Республикасы Конституция суды» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 12 статьяның 3 өлешендә «, Татарстан Республикасы Конституция суды,» сүзләрен «һәм» сүзенә алмаштырырга;

3) 13 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция судына,» сүзләрен төшереп калдырырга.

17 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12);

2) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 1998 елның 30 октябрендәге 1840 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11);

3) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2001 елның 28 июнендәге 947 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 7 – 8);

4) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2001 елның 28 июнендәге 948 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 7 – 8);

5) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2003 елның 21 октябрендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 10);

6) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 елның 20 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш);

7) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2006 елның 15 июлендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш);

8) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларга таләпләрне төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 5 июлендәге 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш);

9) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2008 елның 20 мартындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3);

10) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 3 декабрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 12 (I өлеш);

11) «Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2010 елның 3 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 7 (II өлеш);

12) «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 10 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш);

13) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 11 (I өлеш);

14) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 26 мартындагы 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 3);

15) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 40 һәм 41 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 26 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш);

16) «Татарстан Республикасы Конституция суды эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 1 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 19 (I өлеш);

17) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 17 июлендәге 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш);

18) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 112 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 1 (I өлеш);

19) «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 7 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 37 (I өлеш).

18 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон, әлеге статьяда үз көченә керүнең башка срогы билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 7 – 17 статьялары 2022 елның 31 декабреннән үз көченә керә.

3. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары өч ай эчендә үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль,
2022 ел, 21 октябрь
№ 72-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

## Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз бишенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз бишенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республиканың эчке һәм тышкы хәле турында еллык юлламасы.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 20 октябре
№ 1638-VI ДС

## Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз алтынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз алтынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.

2. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 344-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

3. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 345-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

4. «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында» 348-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Самара өлкәсе арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 30 сентябрендәге 50 номерлы килешүне раслау хакында.

6. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 4 октябрендәге 52/10-Д номерлы килешүне раслау хакында.

7. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 340-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 347-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Конституция судын бетерү, Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчен югалтуын тану турында» 346-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 343-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 331-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 312-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

13. «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 334-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 338-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексына үзгәрешләр кертү турында» 339-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

16. «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 9 һәм 10.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 148135-8 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт (муниципаль) йөкләмәләре нигезендә юл эшләрен башкару максатларында гомумтаралган файдалы казылмалар бирүнең гадиләштерелгән тәртибен билгеләү өлешендә).

17. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 9.21 статьясына үзгәреш кертү хакында» 173718-8 номерлы федераль закон проекты турында (магистраль газүткәргечләрдән дискриминацияләнмәгән файдалану мөмкинлеге кагыйдәләрен (тәэмин итү тәртибен) яисә аларга тоташуның билгеләнгән тәртибен (технологик тоташуны) бозган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

18. «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законның 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 188271-8 номерлы федераль закон проекты турында (югары әзерлек режимын керткән вакытта гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашырганда резервларны куллану мөмкинлеге мәсьәләсе буенча).

19. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 190636-8 номерлы федераль закон проекты хакында (Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен 414-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларын исәпкә алып төгәлләштерү өлешендә).

20. «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 196970-8 номерлы федераль закон проекты турында (орфан авырулардан интегүче пациентларны дарулар белән тәэмин итүне камилләштерү өлешендә).

21. «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 196668-8 номерлы федераль закон проекты турында (орфан авырулардан интегүче пациентларны дарулар белән тәэмин итүне камилләштерү өлешендә).

22.Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 20 октябре
№ 1639-VI ДС

## Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы итеп чикләнмәгән вакытка түбәндәгене сайларга:

Татарстан Республикасы Алабуга суд районы буенча:

3 нче суд участогына – Гыйниятуллин Эльнар Илдар улын.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 20 октябре
№ 1640-VI ДС

# ҮЗӘКТӘ – КЕШЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Тыл, фронттан кала тагын бер тармак – мәгълүмати мохиткә дә кагылдылар. Президент Юлламасында мәгълүмат чараларына бәйле фикер дә яңгырады чөнки. КФУның Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбе деканы, социология фәннәре кандидаты Леонид Толчинский әйтүенчә, җәмгыятьнең дә медиа чараларына сораулары һәм дәгъвалары байтак. «Мәгълүмати сугыш бара. Мәгълүмат чаралары көн тәртибе белән эшли белергә тиеш. Төп нәрсә – мәгънә. Аннан нәтиҗәлелек күрсәткечләрен (КПЭ. – **Авт.**) яңадан карап чыгарга иде. Бар нәрсәне дә трафик белән бәяләгәндә, нинди мәгънә турында сүз булды. Ышаныч, гамәл кылуга этәрү кебек күрсәткечләр өчен эшли башларга иде, – дип саный КФУ мөгаллиме.

Декан сүзләрен медиа өлкәсе белгече, Россия Иҗтимагый палатасы вәкиле Александр Малькевич та хуплады. Сүз уңаеннан, журналист – хәзерге вакытта Херсон өлкәсендә. Шулай да Юлламаны игътибарсыз калдыра алмаган. «Рөстәм Миңнеханов Юлламасының эчтәлекле, актуаль булуына таң калдым. Хәзерге бурычлар моннан берничә ел элек булганнардан да җитдирәк. Хәзер хакимият һәм халык арасында ачык, ышанычлы мөнәсәбәт булдыру мөһим. Бик көчле мәгълүмати һөҗүм чорында бу бик тә актуаль. Рәсми идеология булу мөһим. Республикада моның белән барысы да тәртип, хәтта алданрак та барасыз, дияр идем. Сез ил күләмендә үрнәк күрсәтәсез. Татарстандагы тотрыклылык, тынычлык таң калдырырлык. Ә бит барысы да шушы төшенчәләргә һөҗүм итә. Татарстанда аларга сакчыл караш», – дип искәртте Александр Малькевич.

Моннан тыш, совет әгъзалары гуманитар, мәдәни, IT тармаклар турында сөйләште, сәнәгать, икътисад өлкәләре каршында торган бурычларны барлады. Очрашу нәтиҗәсе бер: бурычлар куелган, юнәлеш билгеле, бердәмлек хисен өстәп, максатка ирешәсе генә калды.

# Бергә җыелганда

## Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест



**Очарга канатландырган, табигатьне күзәтергә өйрәткән, әнине олылаган, хәтта әти-әнидән дөрес итеп энекәш сорарга өйрәткән шагыйрь кем ул? Аның турында ниләр беләбез, нәрсәләрне белеп җиткермибез икән? Шушы тестны үтеп, шагыйрь Роберт Миңнуллин турында белемебезне ныгытыйк әле.**

**1 Роберт Миңнуллинның туган елы?**
а) 1932;
б) 1948;
в) 1954.

**2 Роберт Миңнуллинның туган ягы?**
а) Башкортстан;
б) Татарстан;
в) Кыргызстан.

**3 Университетны тәмамлаганнан соң, 1970 нче елларда шагыйрь Казанда кайсы газетада эшли?**
а) «Татарстан яшьләре»;
б) «Социалистик Татарстан»;
в) «Яшь ленинчы».

**4 Роберт Миңнуллин сүзләренә язылган җыр?**
а) «Туган тел»;
б) «Тәфтиләү»;
в) «Әнкәмнең догалары».

**5 Роберт Миңнуллин «Кызык кеше» исемле шигырен кемгә багышлый?**
а) Сибгат Хәкимгә;
б) үзенә;
в) Ренат Хариска.

**6 Роберт Миңнуллинның «Әрем исе, әрем тәме» шигыре нәрсә турында?**
а) кеше язмышы;
б) табигатьне ярату;
в) авылга кайту.

*Җаваплар: 1) б; 2) а; 3) в; 4) в; 5) б; 6) а.*

### КЕЛӘТТӘ МУЗЕЙ ЯСАГАН ДАМИР ВӘЛИЕВ:

# «ТАРИХНЫ ОНЫТЫРГА ЯРАМЫЙ»

**Яшь буынның тарихка, милли мираска битараф булмавы сөендерә. Шундый яшьләрнең берсе – Чаллыда яшәүче 11 яшьлек Дамир ВӘЛИЕВ. Ул Актаныш районының Адай авылында тарих музее ачкан.**

**:: Дамир, музей ясау идеясе ничек барлыкка килде?**
– Дәү әнием белән бергә «Заброшенная Россия» телеканалын карарга бик яратабыз. Андагы бер тапшыруда алып баручы төрле авыллар буйлап йөри һәм борынгы җиһазлар җыя, ялгыз яшәүче әби-бабайларга ярдәм итә. Шуннан илһамланып, мин дә узган ел җәй көнне, авылга каникулга кайткач, дәү әнидән иске келәт йортында музей ясарга булышуын сорадым. Ул бик теләп ризалашты. Музейны быел эшләп бетердек. Ул әлегә өйнең бер ягын гына алып тора. Киләчәктә аны киңәйтергә телибез.

**:: Тарих белән кызыксынуың нәрсәдән башланды?**
– Тарих белән нәни чактан ук кызыксына башладым. Сугышлар, анда кем катнашкан, Советлар Союзы турында сораша идем. Ташлар, тәңкәләр җыю белән дә мавыктым. Чаллыда без әни белән антиквариат әйберләр сатыла торган кибеткә йөрибез. Аннан тәңкәләр, значоклар, тарих турында китаплар, борынгы купюралар алабыз.

**:: Авыл тарихы музеенда нәрсәләр урнаштырдыгыз?**
– Музейга тарихи ядкәрләр, совет заманнарыннан калган җиһазлар, көнкүреш әйберләрен куйдык. Аларны авылдан, кайсыберләрен шәһәрдән табам. Әби-бабаларымнан калган әйберләр дә күп. Музейда барлык экспонатларны матур итеп киштәләргә урнаштырдык. Авылдагылар да үзләренең авыл тарихына бәйле истәлекләрен китерә.

**КУНАГЫБЫЗ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ**
- Дамир Чаллыдагы 28 нче мәктәпнең 5 нче сыйныфында белем ала.
- Тарих, борынгы әйберләр белән кызыксына.
- Киләчәктә үз партиясен булдырырга тели.

**:: Музейны карарга килүчеләр дә бар, димәк?**
– Әйе, авылдашлар килеп карый, кызыксына. Мин аларга музейны күрсәтәм, экспонатларның тарихын сөйлим. Аларга да, үземә дә бик ошый.

**:: Буш вакытыңда нәрсәләр белән шөгыльләнергә яратасың?**
– Тарих турында китаплар укырга, тарихи урыннарда булырга яратам. Быел җәй көне Татарстан буенча экскурсияләргә йөрдек, күп кенә музейларда булдык. Бабай белән Болгарга, Зөя утравына бардык.

**:: Киләчәктә кем булырга телисең?**
– Тарихчы булырга телим.

**:: Алга таба тагын нинди идеяләрең бар?**
– Безнең республикада борынгы җиһазлар җыю, ялгыз яшәүче әби-бабайларга ярдәм итү идеясен тормышка ашырырга кирәк дип уйлыйм. Ярдәмгә мохтаҗ булган өлкәннәребез күп. Аларга булышырга кирәк. Кешеләр өйләрендәге борынгы әйберләрне дә чыгарып ташламасыннар иде. Бу бит – истәлек. Ватаныбызны, тарихыбызны, милли мирасыбызны сакларга, туган җирне кадерләргә кирәк.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Киңәш-табыш

## Китапка мәхәббәт тәрбиялибез

**Мәгълүмат технологияләре үсеш алган заманда баланы китапка җәлеп итү шактый катлаулыга әверелә бара. Китапны инде күптән телевизор, компьютер, смартфоннар алмаштырды. Ә бит китап уку ул – буш вакытны файдалы үткәрү генә түгел, күзаллауны киңәйтү, хәтерне яхшырту һәм дөрес язарга өйрәнү чарасы да. Баланы китапка ничек җәлеп итәргә соң?**

**Мәҗбүр итмәгез.** Баланы «файдалы» китаплар укытып интектерү кирәкми. Китап уку рәхәт булырга тиеш. Сайлау мөмкинлеге тудырыгыз. Өйдә аны кызыксындырган темага китаплар булсын. Китап кибетеннән балагыз сайлаган китапны сатып алыгыз.

**Үзегез укыгыз.** Укыган әсәрегез турында балага да сөйләгез. Бала яраткан әкият яки хикәяне чиратлап укый аласыз. Аннары баланы уйланырга, фикерләргә этәрә торган сораулар бирегез. Китап уку сезнең өчен дә, балагыз өчен дә матур гадәткә әйләнсен.

**Баланың үз китапханәсен туплагыз.** Галимнәр: «Әти-әнисе китап белән мавыккан көннән башлап, бала да китап укый башлый», – дип раслый. Баланың үз китапханәсен кечкенәдән туплый башлагыз. Укыган китапларны саклап барган очракта, «менә мин укыган китаплар» дип мактанып алу да баланы китап укырга этәрә.

**Китап уку 5–10 минуттан алып 20–30 минутка кадәр дәвам итәргә мөмкин.** Балагызны аңларга тырышыгыз. Кемдер бер сәгать буе әкият тыңлый ала, кемдер

биш минуттан артыкка чыдамый. Балагызны көч белән укытырга тырышуның файдасы булмаячак.

Хикәя

## «Салат»

Әнисе әйләнеп кергән арада, кечкенә Расих тәлинкәсендәге итле токмачны чәй чокырына тутырып куйган иде.

– Нәрсә бу? – диде әнисе, гаҗәпләнеп.

– Салат, – дип авыз ерды малай.

– Алайса, ашыйсың инде хәзер шул салатыңны, – диде әнисе кырыс кына.

Расих үзе уйлап тапкан «кызык»ның болай тәмамлануын бөтенләй дә көтмәгән иде.

– Аша, аша.

Малай, зур күзләрен тутырып, бер әнисенә, бер чокырдагы «салат»ка карап куйды. Әнисенә Расихның кызыгы бер дә ошамаган күренә, йөзе ачулы. Ә салат... Малай баллы чәйдә йөзеп йөрүче токмач кисәкләренә карап куйды. Йөзе авызына бер зур лимонны тутырган кешенекенә охшап калды. Алдындагы боламык бер генә дә аппетитны уятырлык түгел иде шул.

– Әйе, әйе, аша салатыңны! – Әнисенең чигенергә исәбе юк иде кебек.

Малай, йөзен чытып, кулына кашыгын алды. Кашык әкрен генә, чокырдагы боламыкны болгата башлады: анда-монда, аска-өскә... Ләкин авызга таба барырга ашыкмады. Әниләренең тавышын ишетеп, Расихның абыйсы белән апасы да шым булды: әллә чынлап та шул тәмсез нәрсәне ашатачак инде әниләре?!

– Уйнап утырма, әйдә, аша! – Әнисенең боерыгы малайның өметен бөтенләй сүндерде. Ул әкрен генә чокырдагы токмачлы итне кашыгына алып, үтә дә чирканыч нәрсәне күргән кеше сыман, әнисенә карады: бәлки, шаяра гынадыр?! Бәлки, хәзер көлеп җибәрер?.. Әнисенең көләргә исәбендә дә юк иде.

Энесенең бу газаплы кыяфәтен күргән Рәмис түзмәде:

– Расих, әллә почмакка гына басасыңмы соң? – дип куйды.

Шул ук мизгелдә бу хәлдән котылып калуына бөтенләй өмете калмаган Расих ялт итеп урындыгыннан сикереп тә торды, почмакка барып та басты. Ай күрде, кояш алды!

Әнисе авыз ачып бер сүз дә әйтергә өлгерми калды хәтта.

Почмакка карап баскан Расихның шатлыктан ерылган авызын да күрмәде ул.

Малайны еш кына үзе янында күрергә гадәтләнгән Почмак аптырап куйды. Әлегә кадәр ул малайны я елаган, я йөзенә төрле гримасалар ясап, кемнедер үчекләгән кыяфәттә генә күрә иде. Зуррак малай белән кызның нигә җиңел сулап куюын да аңламады ул. Аш бүлмәсендәге әниләренең ирен читенә кунган елмаюын күргәч, бөтенләй гаҗәпләнде. Кызык инде бу кешеләр: гел үзгәреп торалар, аңлап та өлгерә торган түгел.

Лилия ФӘТТАХОВА

Безгә язалар

## Әниемә бию багышлармын!

Минем әниемә рәхмәт әйтәсем килә. Эше күп булса да, мине бию түгәрәгенә, бассейнга йөртә. Безнең хореография төркеме һәр елны «Йолдызлык» конкурсында призлы урыннар ала.

Минем әнием ягулык салу станциясендә эшли. Кайчак төнге сменага туры килә. Без апаларым белән өйдә аңа эш калдырмаска тырышабыз. Идәнне юабыз, тәмле ризыклар пешерәбез, еш кына әнигә күңелле сюрпризлар әзерлибез. Әтием белән әнием исән-сау булсыннар! Без аларны бик яратабыз! Сезнең йөзегезгә кызыллык китермәбез! Әнием, зур үскәч, мин зур сәхнәдә чыгыш ясармын һәм сиңа биюемне багышлармын!

Мәдинә ӘФЛӘТҮНОВА.
Буа шәһәре

Башыңны эшләт!







Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 6715 данә**
**Гомуми тираж – 15318 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 356

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**
**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-73, 222-09-67** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы
**222-09-67** – фән һәм мәгариф
**222-09-64** – әдәбият, сәясәт һәм дин
**222-09-66** – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
**222-09-67** – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+